


# Истәлекләр

Намик Шаммасов

Намик Шаммасов

# Истәләкләр

Әлмәт, 2011 ел

-

Флорида, 2023 ел

## Юллар

Аннотация 2

Рәсемнәр 2

Кабан күле малайлары 3
Кабан күлендә «сәкләр» 6
**Бәрәңге авылында сөргендә 7**
**Герман-парикмахер 9**
**Усиядән - туган йортка 11**
**Мәшәкатьле уку еллары 13**
**Тагын бер кат Шаммасовлар турында 16**
**Беренче бару 18**
**Калифорния татарлары җәмгыяте 21**
**Монда да татар эзе 24**
**Безнекеләр Япониядә 26**
**Мөхәммәтсафа хәзрәт кызы 28**
**Еллар аша… 29**
**Фоторәсемдә әти-әниемне таныдым 29**
**Укытучы Шаммасовлар 30**
**Гомерлеккә күңелемә кереп калдылар 31**
**Мөгаллим Шаммасовлар 33**
**1991 ел, 19 август 35**
**Яшьлегем каласы 37**
**Тычканлы аш 38**
**Горур кәҗә 41**

Annotatsiyä 46
Qaban küle malayları 47

## Аннотация

Бу китаптагы язмаларның авторы нигездә бер кеше - бу көндә Америка Кушма Штатларында улы гаиләсендә гомер итүче Нәмикъ Шаммасов. Әмма китапта аның хатыны Наилә белән бергә язганнары да, энесе Марат Шаммасов язган истәлек тә, Шаммасовлар гаиләсе турында журналист Ф. Мөхәммәтова очеркы да урын алган. Төрле елларда, төрле газеталарда басылып чыккан язмалар гомерләрен укытучылык эшенә багышлаган өч туган - Наядь, Нәмикъ һәм Марат турында, аларның әти-әниләре, гомерләрен халык мәгарифенә багышлаган Хәлил һәм Мөсаффа Шаммасовлар турында булса да, аларның язмышлары аша без күп нәрсәләр белән танышабыз. Күңелле дә, гыйбрәтле дә балачак еллары, сугышка кадәрге шомлы репрессия чоры - бер гаепсез кешеләрне кулга алу, юк итүләр дә, сугыш чоры авырлыклары да, океан артында тормыш итү үзенчәлекләре дә - һәммәсе-һәммәсе кеше язмышлары аркылы җанлы булып күз алдына баса, бер гаилә тормышында ил язмышы чагылыш таба.

Язмалар тематик һәм хронологик яктан мөмкин кадәр эзлеклелек белән тәкъдим ителә.

Рәсемнәр

Шаммасовларның гаилә архивыннан алынган рәсемнәрдә: күршеләр белән 1940 елда бергә төшкән фотода авторларның әтисе һәм әнисе (артта, уңнан беренче һәм икенче, язмада телгә алынган Тәзкирә апа - алгы рәттә, сулдан беренче). Абыйлы-энеле Нәмикъ һәм Марат Шаммасовлар үзләре туып-үскән йорт янында. Мәрҗанидан соң да күпләрне үзенә сыендырган тарихи йорт.

## Кабан күле малайлары

Без, өч бертуган малай, иске Казанда Каюм Насыйри урамын - дагы 10 нчы йортта туып үстек. Балачак һәм күршеләр бер дә истән чыкмый.

Күршеләр дигәндә, әлбәттә, беренче чиратта Тәзкирә ападан башларга кирәк. Тәзкирә апа бу йортта яшь чактан ук Борһан муллада асрау кыз булып хезмәт итә башлаган. Ул яши торган кечкенә генә бүлмә элек хуҗалар өчен чәй әзерләү урыны булган. Мәшһүр татар язучысы Галимҗан Ибраһимовның да, Борһан муллага килгәндә, шушы бүлмәгә кереп чәй эчә торган гадәте булган.

Без белгәндә Тәзкирә апа больницада санитарка булып эшли иде. Безнең урамда гына түгел, ә Казанның бүтән иске урамнарында да аны беләләр иде. Ул бик ачык күңелле хатын булып, килгән бер кешене чәй эчермичә чыгармый иде. Шуның өчен дә сугыш башлану белән Тәзкирә апа өчен иң зур күңелсезлек - аш-су әзерләп, Коръән укыта алмау булды. Тәзкирә апаның бездән берничә яшькә олырак Сөембикә исемле кызы барлык өй эшләрен башкарып тора. иде. Бала чактан ук ул безнең ише күрше малайларын үз туганнары кебек күрде: безне киендереп бакчага озату һәм каршы алу һәрвакыт аның өстендә иде. Гомумән, Сөембикәгә дә, әнисе кебек үк, самимилек, саф күңеллелек хас булды.

Киң күңелле Тәзкирә апа тугыз квадрат метрлы бүлмәсендә аерылган иренең әтисен, әнисен һәм көндәшенең минем яшьтәге Камил исемле малаен да сыйдырып яшәде. Шул ук бүлмәдә Тәзкирә апаның авылдашы Камәрия апа да ун елдан артык торды. Камәрия апа башта санитарка булып эшләде, ә сугыш алдыннан, йөрәк чире аркасында, эшли алмады. Сугыш башлану белән аның кечкенә генә пенсиясен дә бирмәс булдылар. Ул көн саен керосин чиратына йөри иде. Чират «сатып», литрына 1 тиен керем алып тора башлаган иде, ләкин озак та үтмәде, салкын тидереп кайтты да, берничә көннән үлеп тә китте. Күршеләр аны җыелышып күмделәр, чөнки аның бер туганы да, бер сум акчасы да юк иде.

Сугыш башлану белән, җиденче сыйныфтагы Камил, укуын ташлап, сату эшенә керде һәм үз әнисе гаиләсенә - Яңа бистәгә кайтып китте. Шулай итеп, Тәзкирә апа бүлмәсендә алты кешедән дүртәү калдылар.

Гомумкоридорда Тәзкирә апа бүлмәсенә керүче ишек яңагына терәлеп торучы су мичкәсе һәм юынгыч - икенче күршеләрнеке. Аларның фатир ишеге коридорның түрендә. Ирле-хатынлы Фәррах абый белән Наҗия апа, кызлары Ляля (Ләлә түгел, нәкъ менә Ляля), малайлары Рафаэль белән шул фатирда торалар. Фәррах абый, гомере буе кибеттә эшләп, гаиләсен яхшы тәэмин итеп торды.

Сугыш башланып, гомуми мобилизация игълан ителү белән, Фәррах абый костюм урынына гимнастерка киде, лейтенант кубиклары тагып йөри башлады. Хатыны Нәҗия апа белән алар гел әйткәләшеп, ызгышып тордылар. Бәлки шул сәбәптәндер, Фәррах абый өйдә сирәк күренә иде (әллә киресенчә, өенә сирәк кайту сәбәпле сүз чыга торган булгандыр). Аның каравы, Нәҗия апа бер вакытта да эшләмәде һәм, көне буе өендә булып, күршеләргә тынгылык бирмәде. Ул, Надежда исемле марҗа булып, татар авылында тәрбияләнгән. Кияүгә чыкканда, мөселман динен кабул итеп, Нәҗия исеменә язылган. Урысчасы шәп. Шул ук вакытта ишегалдындагы икенче бинада яшәүче урыс теле укытучысы урыс телен остарак белә, ләкин ул Нәҗия апа белән сөйләшү генә түгел, очрашмаска да тырыша иде.

Ул укытучының ире элек югары урында эшләде. Эшкә дә автомобиль белән генә алып китәләр иде. 1937 елда аны «халык дошманы» дип гаепләп кулга алдылар һәм озак та тотмыйча аттылар. Шуннан соң аның ике бала (безнең яшьтәшләр) белән калган хатынын укытучылык эшеннән кудылар, гаиләсен, дүрт бүлмәле фатирдан чыгарып, бер генә кечкенә бүлмәдә калдырдылар. Минем әни, укытучы буларак, ул хатын белән урамда гына очрашып сөйләшә иде. Нәҗия апа күрүеннән куркып, алар бер дә безнең фатирда очрашмадылар, чөнки Нәҗия апаның «органнарга» барлык күршеләр турында хәбәр җиткереп торуы билгеле булган.

Нәҗия апа, көне буе өйдә торып, гомумкоридорга керүчеләрне үзенең дәфтәренә язып бара иде. Шул хисаплар нигезендә ул гомумкоридор идәнен юмый, коридордагы лампочкага акча түләми иде. Бервакыт шулай, 1940 елда, әтинең туган авылы Чулпаннан килгән ике кешене кунак итү 21 гыйнварга туры килде. Кунак өстәле артында утыручылар әкрен генә җырлый башлагач, Нәҗия апа ишекне кагып: «Юлбашчыбыз Ленин үлгән көндә ничек күңел ачып утырырга мөмкин? Хәзер үк тиешле урынга хәбәр итәм!» - дип кычкырды. Билгеле, шундый куркыныч кисәтүдән соң мәҗлес халкы тиз-тиз җыенып, кайсы кая таралышты. Элек тә, 1937 елда кулга алынып, бер ел утырып чыкканнан соң әти политика турында сөйләшми торган булды.

Бер генә явыз күрше барлык матур дөньяны, күңелле дусларны җиңә алмый иде, әлбәттә. Бала чактан ук еш аралашкан кайбер күршеләрне дә әйтеп узасы килә.
Без, балалар, авырый башласак, бер табиб килеп карый иде. Ул табиб урыс булса да, татарча яхшы аңлаша һәм аны халык телендә «Күгәрчен» дип атыйлар иде.

Ирләр өчен алучы Герман кушаматлы бер парикмахер да бездә булгалый иде. Ул бик ачык күңелле, күпне күргән, беренче герман

сугышында катнашып, әсирдә булып кайткан кеше иде. Парикмахерлык һөнәрен ул әсирлектә үзләштергән һәм үз эшен бик яратып башкара иде. Сугыш башлану белән аны кулга алып, шпионлыкта гаепләп, төрмәдә атуларын безгә соңыннан аның яшь хатыны Рәббига апа сөйләде. Тукай урамында торучы Шакир абый хатыны Сәрвәри апа белән безгә еш кына киләләр иде. Шакир абыйларның үз балалары булмады, шуңа күрә безне үзләренә чакырып, үзе ясаган радиоалгычны күрсәтә иде. Радиоалгыч бер метр чамасы биеклектәге һәм киңлектәге бер агач тартма эчендә тора, зур лампочкалардан җыелган. Минем әтигә шул радиоалгыч аша Төркиядән тапшырылган гарәп телендәге Коръән укулар бик ошый иде. Сугыш башлану хәбәрен дә Шакир абый Төркия радиосыннан 22 июньдә иртән үк ишетеп, безгә хәбәр иткән иде. Ләкин сугыш башлану белән Шакир абыйны, радиоалгычы белән бергә төрмәгә алып киттеләр, ә озак та үтмәде, Сәрвәри апа аның төрмәдә атылу хәбәрен килеп сөйләде.

Шул вакытта аралашкан барлык күршеләрне санап бетерү мөмкин түгел. Шулай да безнең күңелдә сакланган Шәүкәт турында әйтмичә булмый. Ул узенең намуслылыгы белән аерылып торды. Безнең олы абыебыз Наядь һәм Шәүкәт икесе дә оста оештыручылар иде. Алар, кечерәк балаларны «Чаткы» кинотеатрына алып барып, яңа фильмнар карауны оештыралар иде. Шулар арасында «Чапаев»-ны 13 мәртәбә карау, «Вратарь», «Трактористы», «Веселые ребята» һәм башка шундый фильмнарны карау истә калган. Ә җәйге каникул чорларында Шәүкәт белән Наядь футбол ярышлары оештыралар иде.

Тик шунысы кызганыч, сугыштан соңгы елларда Шәүкәт, хәмер белән мавыгып китеп, вакытсыз вафат булды.

Безнең ишегалдында икенче бинаның аргы башында 45-50 яшьтәге Хәсән абый яшәде. Сугышка кадәрге чорда бу абзый безнең өчен армас-талмас хезмәт кешесе булып истә калды. Ишег-алдындагы кечкенә генә алачыгында ул нәрсәдер ясый, төзәтә иде. Соңыннан без аның оста куллы калайчы, кургаш белән ябыштыручы, буш консервы савытларыннан төрле соскылар, кружкалар, бүрәнкәләр ясаучы икәнлеген белдек. Аның һәр ясаган әйбере матурлыгы һәм югары сыйфаты белен аерылып тора иде.

Насыйри урамындагы 10 нчы йорт - ул безнең туган йортыбыз.

Без торган йорт - тарихка кереп калган олы дин әһеле, философ, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани йорты да әле ул. Ул вафат булгач, революциягә кадәр монда Борһан мулла яшәгән.

Гомер уза, заманалар үзгәрә. Безнең белән күрше булып яшәгән гаиләләрнең барысы да диярлек бу йортта юк инде. 2001 елның июлендә без, абый белән Казанга баргач, күршебез Ляляны һәм

Шәүкәтнең хатынын күрдек. Алар да хәзерге көндә башка урынга - Казандагы яңа йортларның берсенә күчерелгән булырга тиешләр.

**Нәмикъ ШАММАСОВ,**
**сугыш һәм хезмәт ветераны, техник фәннәр кандидаты.**
**Марат ШАММАСОВ,**
**хезмәт ветераны, РСФСРның мәгариф отличнигы.**
**Сарман районы, Җәлил бистәсе.**

Шаммасовларның гаилә архивыннан алынган рәсемнәрдә: күршеләр белән 1940 елда бергә төшкән фотода авторларның әтисе һәм әнисе (артта, уңнан беренче һәм икенче, язмада телгә алынган Тәзкирә апа - алгы рәттә, сулдан беренче). Абыйлы-энеле Нәмикъ һәм Марат Шаммасовлар үзләре туып-үскән йорт янында. Мәрҗанидан соң да күпләрне үзенә сыендырган тарихи йорт.

## Кабан күлендә «сәкләр»

**Әлеге язманың авторы Нәмикъ Шаммасов озак еллар төзелеш инженерлары институтында укыта, техник фәннәр кандидаты. Хәзерге вакытта ул хатыны Наилә ханым белән ерак Америкада уллары Айрат тәрбиясендә яши. Аның истәлек дәфтәреннән бу өзекне безгә Сарман районының Җәлил бистәсендә гомер итүче энесе Марат Шаммасов тәкьдим итте. Язма 1000 еллык Казаныбыз тарихының безгә мәгълүм булмаган якларын чагылдыра.**

Чыңгылдап пыяла ватылган тавыш ишетелде һәм тәрәзә алдына йодрык хәтле таш килеп төште. Шулвакыт ишектә күрше класста укучы Шәүкәт күренде. Ул миңа карап: «Нәмикъ, сәкләр килгән, классыгыздагы малайларны җый! Наядь анда укучыларны күтәрә, ә мин Мәхмүтләрне чакырып киләм», - диде. Наядь 4 нче класста укый, ул минем бертуган абыем һәм мәктәп малайларының юлбашчысы. Ә «сәкләр» дип Суконный бистәсендә яшәүчеләрне атыйлар иде.
Без урамга чыкканда Наядь янына башка класс малайлары җыелган иде инде. 1936 ел иде бу. Мин ул чакта элекке Күл буе

мәдрәсәсе бинасында урнашкан татар мәктәбенең 3 нче классында укыйм. Ул фасад ягы белән Кабан күленә карап тора. Без шул бинадан чыгып күл ярында тезелеп бастык. Боз өстендә җыелып торган сәкләрне күзәттек. Күп тә узмады, Насыйри тыкрыгыннан безнең якның 4-5 егете ярдәмгә килеп җитте. Без алар артыннан: «Кабан наше, не ваше, сәкләргә тау башы», - дип кычкыра-кычкыра аларны куып киттек. Күлнең уртасына җиткәч, кире борылдык. Ә

укучылары арасында гына түгел, ә укытучылар тарафыннан да ихтирам казанды. Шулай бервакыт, Наядьның рус теленнән авыр укуын белгәч, укытучы Мәргубә Колахмәтова аны үз өенә чакырып өстәмә дәресләр уздыра башлады. Шул ярдәмне онытмыйча, Наядь тә күп еллар дәвамында Мәргубә апаны олылады. Хәтта ул Уфа нефть институтында кафедра мөдире булып эшләгәндә дә Казанга килгән саен Мәргубә апа янына кереп хәлен белә иде.

Менә шулай татар егетләре, ике чор дәвамында үз милләтенең горурлыгын саклап, Кабан күлендәге көрәшләрдә актив катнашып, олыгайгач та дәрәҗәле кешеләр булып хезмәт итәләр.

## Бәрәңге авылында сөргендә

1932 елның август аенда безнең квартирга милиция кешеләре килеп тентүләр ясадылар, барлык китапларны,язу-сызуларны, өстәлдә эскәтер астында яткан хатларга кадәр тикшерделәр. Ике көн рәттән актарынганнан соң әтине үзләре белән алып киттеләр.

Берничә көннән әниебез әтинең Пләтән төрмәсендә утыруын белешеп кайтты. Шуннан соң әни я Наядьне, я мине ияртеп әтигә передачалар илтеп йөрде. Безгә әти белән күрешергә рөхсәт итмәделәр.

1933 елның июнь аенда әти өйгә кайтты. Төрмәдәге хәлләрне ул болай сөйләде. Тикшерүче сорау алганда төрле документларга куелган ялган (поддельный) имзаларны әтинең кулы дип танытырга тырышкан. Мулла малае булган өчен соңга таба әтине милләтчелектә гаепләргә маташкан. Тикшерүче сорау алырга төнлә чакырта, пистолетын өстәлгә куеп «эшкә» тотына икән. Азат итәр алдыннан тикшерүче әтигә гаиләсе белән Казаннан ике елга сөрелүен әйткән, ягъни без мәҗбүри рәвештә Казаннан 2 елга китеп торырга тиеш икәнбез. Шулай итеп, 1933 елның август аенда без гаиләбез белән Мари республикасындагы Бәрәңге авылына килеп урнаштык.

Бәрәңге район үзәге, татар авылы, анда яңа педучилище

ачылган иде. Әти белән әни икесе дә шунда укытучы булып эшли башладылар. Әти физика укытты, әни татар теленнән дәресләр бирде.

Авылга килү белән әти район эчке эшләр бүлеге җитәкчесе Хустин янына кереп, үзенең Казандагы хәлләрен сөйләп, монда мәҗбүри җибәрелүен хәбәр итеп чыкты. Аның яныннан кайткач, әти бик шатланып болай дип сөйләде: «Иптәш Хустин бик мәгълүматлы кеше булып күренә. Итагатьлелеге белән дә Плэтән төрмәсендәге тикшерүчеләрдән югарырак тора».

1934 елның сентябрендә Наядь мәктәптә 3-нче класста укый башлады. Укый-яза белүемне искә алып, мине дә 2нче класска алдылар. Үз классындагы укучылар белән бергә Наяд кышын чаңгыда район авыллары буйлап агитколлективта йөрде. Алар С.М. Кировның үтерелүен халыкка хәбәр итеп йөрделәр.

Ике елдан соң, уку елы бетүгә без ашыгыч рәвештә Казанга кайтып китәргә җыена башладык. Ә без, малайлар, җәйне авылда балык тотып, җиләк җыеп, ял итеп уздырырга уйлаган идек. Әнидән болай ашыгуның сәбәбен сорагач, җавабы кыска булды: «Иптәш Хустин әтиегезгә шулай кушкан». Иптәш Хустинның ашыктыру сәбәбен без соңрак, берничә ел үткәч кенә аңладык.

1935 елның августында без Казандагы элекке квартирыбызга кайттык. Без югында анда яшәгән Салих абый гаиләсе Болак буендагы бүтән квартирга күчеп китте. Әни Казан педагогия институтында укуын дәвам итте. Әти Киров районындагы урта мәктәптә физика укытучысы булды. 1935-36 уку елында элекке Күл буе мәдрәсәсе бинасында урнашкан татар мәктәбендә Наядь 4нче класста, мин 3нче класста укый башладык.

Бәрәңгедән бөтенләйгә күчеп китсәк тә, андагы күп таныш-белешләр Казанга килгәндә безгә кереп чәй эчеп чыгалар, андагы фаҗигале хәлләрне сөйлиләр иде. Ул вакытта Бәрәңгедә үткәрелгән репрессиягә эләккән авыл җитәкчеләре, укытучылар турында газеталарда мәкаләләр басылып чыкты. Шулар арасында без белгән кешеләр: педучилище директоры Таһир Мәхмүтов, педучилищедан завуч Каюм Бигәшев, урта мәктәп директоры Нәҗметдинов, урта мәктәп укытучысы Габдулла Ижбулатов та бар иде. Алар барысы да кулга алынып атып үтерелгәннәр. Бәрәңге авылын оештыручыларның берсе укымышлы мулла Баязетдин Гаязовка шулай ук «милләтче» дип гаеп такканнар, атып үтергәннәр. Соңыннан бу кешеләр реабилитацияләнде. Ул вакытта милләтебезнең тарихын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә, саклап калырга омтылучы фән һәм дин әһелләренә шулай репрессиягә эләгү куркынычы янап тора иде.

Бәрәңге районының МВД бүлеге җитәкчесе Зиннәт Хустинның югарыдан килгән репрессия боерыкларын үтәргә вөҗданы кушмаган. Ә боерыкны үтәмәгән өчен үзенә үлем җәзасы янавын ул яхшы белгән, нәтиҗәдә кабинетында үзен үзе атып үтергән.

1936-1938 еллардагы репрессияләр кабатланмасын өчен гаепсез эзәрлекләнгән, үтерелгән шәхесләрне онытмаска, истә тотарга кирәк. Ул елларда репрессия тегермәненә эләккән миллионнарча гаепсез кешеләр үзебезнең әти-әниләр, әби-бабайлар бит.

**Герман-парикмахер**

Үткән гасырның 30нчы елларында безнең гаилә Казан шәһәрен-дә К. Насыйри урамындагы 1Ончы йортның 4нче квартирында яшәде. Шул елларда безгә даими рәвештә бер чәч төзәтү остасы килеп йөрде. Беренче бөтендөнья сугышында катнашып, Германиядә әсирлектә булып кайткан өчен аны «Герман» дип йөртәләр, бу кушамат аңа тәмам ябышкан иде.

Герман безгә билгеләнгән вакытка килеп җитә, әтине идән уртасындагы урындыкка утырта, кечкенә чемоданын ача, чәч төзәтү коралларын җәеп сала да эшкә керешә. Агалы-энеле өч малай - без, читтәрәк утырып, парикмахерның эшләгәнен күзәтәбез, аның үзе турында сөйләгәннәрен кызыксынып тыңлыйбыз.

Ул фронтта яраланып әсирлеккә эләккән икән. Немец госпитальләрдә озак кына дәвалангач, аны бер немец гаиләсенә эшкә бирәләр. Хуҗа немец әсир татарның тырышлыгын, пөхтәлеген бик тиз күреп ала, аны үзенә ярдәмгә парикмахер һөнәренә өйрәтә. Озакламыйча татар кешесе оста чәчтараш булып җитешә.

Сугыш бетеп, әсирләрне туган илләренә кайтарыр вакыт җиткәч, немец татар-әсиргә Германиядә калырга, үзе белән бергә эшләргә тәкъдим иткән. Ләкин әсир ризалашмый, хуҗага рәхмәт әйтеп, туган җиренә, Казанга кайтасы килүен белдерә. Саубуллашкан чакта немец әсиргә кечкенә генә чемодан белән Германиядә эшләнгән чәч алу кораллары җыелмасы бүләк итә. Үз иленә кайтуга элекке әсир Казан шәһәренең Яңа бистәсендә үзенең чәчтарашханәсен ачып җибәрә, ә «Герман» сүзе аның кушаматы булып кала.

Әтинең чәчен алган арада Герман чит илдәге тормышның гыйбрәт алырлык күренешләрен сөйли иде. Мәсәлән, Германиядә эшкә килгән төрек гаиләләренә мәчетләр салырга, ислам дине таләпләрен үтәргә, шәригать кушканча яшәргә, һәркемгә күңеленә

хуш килгән кәсеп белән шөгыльләнеп, матур тормыш корырга мөмкинлек бирәләр икән.

Мондый сүзләрне ишеткәч, әти, чәчтарашны сүзеннән туктатып чит илдәге тормыш турында фикерләрен кычкырып сөйләмәскә киңәш бирә, мондый сүзләрне хөкүмәт кешеләре, органнар пропаганда дип исәпләргә мөмкин дия иде. 1938 елдан Герман-парикмахер безгә килми башлады, без аның турында хәбәрсез калдык.

Аның хәбәре безгә күп гомер үткәч килеп иреште. 1978 елда без гаиләбез белән Г. Ибраһимов проспектындагы квартирга күчтек. Яңа күршеләребез Кәшшаф абый белән Рәбига апа икесе дә бик ачык табигатьле кешеләр, олы яшьтәге пенсионерлар булып чыктылар. Кәшшаф абый Ватан сугышында яраланып кайткан, инвалид, көннәрен күбесенчә караватында ятып, радио тыңлап уздыра. Рәбига апа исә көннәр буе кергән кешеләр белән сөйләшеп, буш вакытларында китап укып та утыра. Квартирларының ишеге көндез һәрвакыт бикләнмәгән була, күршеләр гадәттә аларга ачкычларын калдырып китәләр.

Беренче танышуда ук Рәбига апа үзенең тормыш юлын сөйләп бирде. Ул кече яшьтән үк ятим калган, 14 яшеннән татар гаиләсендә бала карап хезмәт иткән. Күршеләр киңәше белән Рәбига 16 яшеннән татар парикмахеры гаиләсенә асрау кыз булып килгән. Хуҗа хатын каты авыру булып урын өстендә яткан. Хуҗа чәчтараш булып эшли, халык телендә исеме Герман икән. Рәбига авыру хатынны бер ел караган, ә ул вафат булгач, Герман-парикмахер Рәбигага хатыны булырга тәкъдим иткән. Шул рәвешле алар бер гаилә булып яши башлаганнар. Ул чакта Германның үз чәчтарашханәсе булган, Рәбига шунда җыештыру, юу, себерү эшләрен башкарган.

Герман белән Рәбиганың бер малайлары туган, тик гомерле булмаган, 12 яше тулганда авырып үлгән.

1925 елда Германның хосусый чәчтарашханәсен национализацияләгәннәр, дәүләтнеке иткәннәр, Германның үзенә шунда гади чәчтараш булып эшләргә рөхсәт иткәннәр. Дәүләткә эшләү өстенә Герман элекке клиентларының өенә йөреп тә хезмәт күрсәткән, шуларның берсе безнең әти булгандыр инде.

1938 елда, Германны кулга алып, Пләтән төрмәсенә япканнар, бөтен милкен конфискацияләгәннәр. Рәбиганы сорау алуга чакырып, «Ирең пистолетын кая яшерде?» дип тинтерәткәннәр. Рәбига: «Мин аның пистолетн күргәнем юк», дип җавап бирә, ә сорау алучы атна саен чакыртып шул ук сорауны кабатлый икән.

Шул допрослардан котылу чарасын эзләп, Рәбига бер иптәш

хатынына мөрәҗәгать иткән. Тегесе мондый киңәш биргән: «Аның пистолеты ыштан төбендә, мин бүтән пистолетын белмим», - дип әйт син аларга дигән. Чираттагы допроска баргач Рәбига иптәш хатыны өйрәткән сүзләрне ярып салган. Шул сүзләрдән соң сорау алучы бик каты ачуланган, Рәбиганы хулиган дип, башка әшәке сүзләр белән сүгеп, кабинетыннан куып чыгарган, сорау алырга бүтән чакырмаган.

1941 елның башында, Рәбиганы төрмә капкасына чакыртып, иренең киемнәрен тапшырганнар. Бер таныш милиционер ире Германның шпионлыкта гаепләнеп атып үтерелүен әйткән.

Менә шулай тырыш, эш сөючән парикмахер Герман фаҗигале үлемгә дучар була - туган җире Казанда бер гаепсезгә атып үтерелә. Аның хатыны Рәбига гомеренең соңгы көннәренә кадәр беренче ирен - Герман-парикмахерны җылы сүзләр белән искә алды, ходайдан аңа җәннәтләр сорап догалар укыды.

## Усиядән - туган йортка

**Без гаиләдә өч малай үстек. Яшь араларыбыз икешәр ел. Иң кечесе мин - Марат, уртанчыбыз Нәмикъ һәм иң олыбыз Наядь. Туганнан бирле 1943 елга кадәр Казанның Каюм Насыйри урамындагы 10 йортта яшәдек. Буйортка 60-70 нче елларда гына игътибар итә башладылар. Чөнки аны татар халкының бөек мәгърифәтчесе, тарихчы һәм философ Шиһабетдин Мәрҗәни салдырган, 1858-1889 елларда шунда яшәгән.**

**Хәзерге көндә без торган Мәрҗани йортының хәле элеккедән әллә ни аерылмый: капкасын тимердән ясаганнар да ишек алдына асфальт җәйгәннәр. Казанның 1000 еллык юбилеена без бу йорт чын-чынында архитектура һәйкәле булыр дип уйлыйбыз. Бүген «Мәгърифәт» укучыларына абыем Нәмикънең истәлек дәфтәреннән бер сәхифә тәкъдим итәм. Казаныбыз юбилее алдыннан ул укучыларга кызыклы булыр дип өметләнәм.**

**Марат ШАММАСОВ.**<br>
**Җәлил бистәсе,**<br>
**Сарман районы.**

1942 елның августы. Пароход, ниһаять, Казан пристанена туктады. Яр буендагы суда мазут таплары, агач кисәкләре йөзеп йөри. Ярдагы ком өстендә чүп-чар, чүпрәк-чапрак һәм пыяла

ватыклары күп. Гомумән, тирә-як күптән инде җыештырылмаган. Шулай да ярга төшеп, туган як җиренә аяк басу үзе җанга җылылык бирә.

Казан пристане Бишбалта бистәсендә урнашкан. Пристань тирәсен Казан халкы, русча «устье» сүзеннән алып, Усия дип тә йөртә. Усия халык өчен Иделгә чыгу капкасы гына түгел, ә ял итү урыны да. Менә язгы боз кузгалу вакыты җитә. Шәһәрдәге трамвай вагоннарына боз агуын карарга өндәүче плакатлар эленә. Халык Казансу күпере һәм Бишбалта дамбасы буйлап, трамвай вагоннарына тулып яисә җәяүләп, Усияга агыла. Идел ярларыннан тальян гармуны, җыр тавышлары ишетелеп тора. Кайбер гаиләләр, яр буенда самавыр шаулатып, чәй дә эчеп утыралар. Иделдә боз кузгалу - шәһәр халкы өчен үзе бер бәйрәм.

Менә матур җәй килә. Усия тирәсендә ял итүче халык күбәя. Алар Маркиз дип аталган ком утрауларына юнәлә. Аның чиста комы, сөзәк ярлары кешеләргә су коену, ял итү өчен махсус ясалган диярсең. Су трамвайлары ял итүчеләрне Усия белән Маркиз арасында көне буе арлы-бирле ташып тора.

Билгеле, мондый күңелле хәлләргә сугыш нокта куйды. Хәзер исә минем тизрәк өйгә кайтып җитәсе, туганнарны күрәсе килә. Бишбалта дамбасы буйлап, балачактан таныш урыннарны күзәтеп җәяү атлыйм.

Татарстан урамының Насыйрига каршы ягында җиргә сеңеп беткән кечкенә генә керосин кибете бар. Шул кибет ишеге төбендә озын чират сузылган. Китергән керосин җитми кала, шуңа күрә чират төн буе саклана.

Насыйри чатындагы ипи кибетенә дә озын чират сузылган. Насыйри урамы, шәһәрнең башка урамнары кебек үк, ярым җимерек хәлдә. Урамга түшәлгән ак таш күптән яңартылмаган, юлда чокыр-чакырлар барлыкка килгән. Урамның ике ягыннан сузылган тротуар да гел чокырлардан тора. Җөп санлы йортлар ягында капкаларның берсе генә сакланып калган, башкаларының баганалары гына тора, безнең йорт капкасының да баганалары читкә янтайган.

Урамның каршы ягындагы йортлар күрер күзгә шактый төзек. Урам чатындагы беренче бина Татарстан урамы буйлап Комсомольская чатындагы җимерек чиркәүгә кадәр сузыла. Ул элек монастырь булган диләр. Чаттан икенче йорт ишшегалдындагы таш бинада район суды урнашкан. Сугышка хәтле Мәрҗани мәчетенең ап-ак стеналары урамга ямь кертеп торалар иде. Хәзер исә, буяуларны яңарту гына түгел, киресенчә, мәчет ишегалдында дегет склады ясаганнар. Мәчет картларына дегет мичкәләре арасыннан узарга туры килә.

Насыйри урамының мәчет чатында су колонкасы куелган. Су

әкрен агу сәбәпле, аның янында халык бер дә өзелми. Моннан алган суны эчәргә генә тоталар. Кер юу өчен Кабан күле буенда урнашкан мойка хезмәт итә. Мойка - калын такта түшәп ясалган зур сал. Ул тимер трослар белән ярга тарттырып беркетелгән. Баштарак сал өстендә түбәле корылма да бар иде, соңрак ул җимерелеп бетте һәм сал өстендә идән генә калды. Җәй көннәрендә мойкада кер юучы хатыннарның кер бәләкләгән тавышлары ишетелеп тора. Кыш көннәрендә дә мойка тирәсендәге бәкеләрдә кер чайкаучылар бетми.

Насыйри урамының мәчеткә каршы чатында ике катлы кечкенә генә агач йортның аскы кат тәрәзәләре җиргә тиеп үк тора. Менә шул йортта күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри яшәгән. Безнең урамга аның исеме бирелгән.

Капкадан кергәч уң кул ягындагы бинаның бәренче катындагы зур тәрәзәләре һәм биек парадный ишеге күзгә ташлана. Сул яктагы бина башкача төзелгән: аның тәрәзәләре кечкенә һәм җирдән ярты метр чамасы гына калкып тора. Бу бинаны төзетүче хуҗа бер гаилә өчен уңайлы шартлар булдыруны күз алдында тоткан булса кирәк. Шушы йортта гаиләсе белән Шиһабетдин Мәрҗани яшәгән. Революция алдыннан йортның хуҗасы Борһан мулла булган дип сөйлиләр.

## Мәшәкатьле уку еллары

Йорт баскычы буйлап менеп, мин гомум коридор ишеген тартып карадым. Ишек ачылырлык, эчтән келәсе эленмәгән булды. Ишек яңагындагы электр лампочкасын яндырып җибәргән идем, үзебезнең ишектәге зур йозакны күреп алдым, Бу хәл миңа гаҗәп тоелды.

Чөнки мин өйдән чыгып китк әндә безнең гаиләдән әтине генә армиягә алганнар иде. Аны, яше олы (48 яшь) һәм исәнлеге начар булуга карамастан, «нестроевой» категориясенә кертеп, Зеленодольскидагы хәрби заводка разнорабочий итеп мобилизацияләгәннәр иде.

Коридорга караган Тәзкирә апа ишегеннән сөйләшкән тавышлар ишетелде. Мин ишекне шакып Тәзкирә апаларга кердем. Ишектән сул якта, мич алдында минем дәү әни утын агачыннан чыра телә иде. Тәзкирә апа үзенең кечкенә самоварын чистарта. Алар: «Нәмикъ кайтты, исән-сау, әйдә, уз!» - дип, шатланып каршы алдылар. Тәзкирә апа самоварын куярга гомум коридорга чыгып китте. Мин үземнең чемоданнан ярты кирпеч ипи һәм калган 200 грамм чамасы

шикәр комын өстәлгә алып куйдым. Чәй эчкәндә дәү әни әтинең һаман Зеленодольскида эшләвен, 18 августта абыем Наядьнең сугышка алынуын, ә август азагында әнинең дә, энем Маратны алып, Юдинодан ерак түгел Җәке исемле татар авылына укытучылык эшенә китүе турында сөйләде. Мин Казаннан чыгып киткәндә, әни эшләгән татар мәктәбен ябып, укытучыларын хәрби заводка разнорабочий итеп җибәргәннәр иде. Хәзер, аның югары белемле татар теле укытучысы булуын искә алып, Җәкедәге татар урта мәктәбенә җибәргәннәр.

Икенче көнне иртән үк пригородный поездга утырып мин әти янына киттем. Анда минем элек тә барганым бар иде. Паратски станциясенә хәтле поезд белән барасың да, аннан ерак түтел общежитие булып калган зур бараклар бар. Шул баракларның берсендә ике катлы озын нарларның бер өлешендә әтинең иске одеялы һәм капчыгы ята. Шул билгеләргә карап, әтинең нардагы урынын таптым. Нар астындагы капчыктан берничә бәрәңге алып, аларны пешереп куярга булдым. Әтинең котелогына су салып, аны барак уртасында янып торган «буржуйка»га утырттым. Тышка чыгып, умывальникта бәрәңгеләрне юдым да кайнап чыккан котелоктагы суга салдым. Озак та үтмәде, әти эштән кайтты. Аның бераз икмәге дә бар икән, шуның белән әле пешкән чикмәнле бәрәңгене ашадык. Мин үземнең пароходта йөреп кайтуларымны сөйләдем. Пароход штурманы миңа 10 нчы классны тәмамлап институтта укырга киңәш бирүен әйттем. Әти шул киңәшкә кушылды һәм: «Син бит тырышып укыйсың, мәктәптә укуыңны дәвам итеп, институтка керү мәслихәт булыр. Ә укуга түләүне ничек булса да оештырырбыз,» - диде. Без әти белән киләсе атнада икәүләп әни янына, Җәке авылына барып кайтырга сөйләштек. Шуннан соң әти, яңадан заводка барып, үзенең цех начальнигы һәм сменщигы белән ризалашып кайтты да ял итәргә ятты. Мин, Паратски станциясенә барып, пригородный поездга утырдым да Казанга кайтып киттем.

Икенче атнаның билгеләнгән көнендә мин иртәнге пригородный поезд белән Юдино станциясенә барып төштем. Элекке сөйләшү. буенча анда әти мине көтеп тора иде инде. Без тиз генә вокзалда үзебез алып килгән берәр кисәк ипи һәм икешәр бәрәңге ашадык та юлга чыктык. Җәке авылы Юдино станциясеннән 25 чакрым ераклыкта диделәр. Димәк, безне 5-6 сәгатьле җәяүле юл көтә. Көн матур, аяз, әти белән янәшә булу һәм әнине тизрәк күрергә омтылулар барысы да безне рухландырдылар. Кичке сәгать 4 тә без Җәке авылына барып җиттек. Анда, кешеләрдән сорашып, укытучы Шаммасованың торган йортын таптык. Ул иске генә агач йорт, хуҗасы бер әби булып чыкты. Озак та үтмәде, әни белән Марат та кайтып керделәр. Әни бәрәңге пешерде һәм без авыл ипие белән туйганчы бәрәңге ашадык,

чәй эчтек. Кичен озак кына сөйләшеп утырдык. Мин Идел буйлап пароходта практикада йөргән хәлләрне сөйләдем. Әни дә миңа яңадан мәктәпнең 10 нчы классына кереп укырга тәкъдим итте.

Иртән сәгать 4 тә торып без әти белән кайту юлына чыктык. Сәгать тугызда Юдино станциясенә килеп җиттек, әниләрдән алып чыккан азыкларны ашадык та, поездга утырып икебез ике якка - әти Паратскига, мин Казанга кайтып киттек.

Сентябрь аена кердек, уку елы башланыр вакыт. Миңа кичекмәстән үзем укыйсы 10 нчы классны табып, шунда укуны дәвам итү турында сөйләшергә кирәк иде. Сугышка хәтле мин Кабан күле буенда урнашкан 12 нче номерлы татар мәктәбендә укыдым. Сугыш башлану белән, ул мәктәпне ябып, аның бинасында госпиталь ясадылар. Укучыларны классы белән төрле мәктәпләргә тараттылар. Безнең 9 нчы классны Яңа бистәдәге 13 нче мәктәпкә куштылар. Минем өчен ул мәктәп шактый ерак һәм укулар да икешәр смена булу 12 нче мәктәп белән чагыштырганда бик җайсыз булды. Ул гына да түгел, кышкы салкыннар башлану белән мәктәпнең җылыту системасы эштән чыкты да, безнең классны 40 нчы, аннан 47 нче мәктәпләргә күчереп, өченче сменада укыттылар. Быел безнең классның яңадан 13 нче мәктәпкә кайтарылуын ишетеп, мин шунда бардым. Миңа дәресләргә йөрергә рөхсәт иттеләр, ләкин иртәгә үк класс белән бергә Лаеш районындагы колхозга эшкә барырга һәм октябрь аена хәтле ярты еллык уку бәясен (150 сум) түләргә кирәк диделәр. Икенче көнне иртән, кечкенә генә янчык тотып, мин мәктәпкә бардым. Анда безне, иске йөк машинасына утыртып, Лаеш районына алып киттеләр. Без эшлисе колхозның клубына урнаштык, кызларны фатирларга урнаштырдылар. Иртән колхоз бригадиры безгә эш урынын күрсәтте. Ул кыр үлән баскан чәчү җире булып чыкты. Анда ниндидер «стратегический» үсемлек утыртылган. Ул үсемлек СК-4 заводына резина ясау өчен кирәк икән. Ул тышкы яктан алоэ гөленә ошаган. Кырдагы үлән арасында аны табуы да кыен. Без тезләнеп үләннәрне кул белән йолкып киләбез дә, алоэга охшаган үсемлекне күргәч, бригадирны чакырып, аңардан таныттырабыз. Шулай итеп, беренче көнне бригадир белән эшләсәк, башка көнне ул безнең янга килмәде. «Сез үзегез грамотныйлар» дип безгә ышаныч белдерде. Без утаган мәйданда кап-кара җир һәм сирәк кенә үсеп утыручы алоэга охшаган үсемлекләр кала иде. Көндез колхоздан безгә бер кружка сөт һәм бер кыяр бирәләр иде. Ике атна шулай эшләп узып китте дә көзге яңгырлар башланды. Безгә кайтып китәргә рөхсәт иттеләр. Бригадир безне бер җиккән ат белән Казанга кадәр озатты.

Октябрь аенда мәктәптә дәресләр башланды. 10 нчы класста барлыгы 12 укучы, шуларның икесе генә 12 нче мәктәптән килүчеләр.

Дәресләр икенче сменада, ягъни төштән соң гына уздырыла. Дәресләрдә пальтоларны киеп утырабыз. Салкынлык тагын да көчәеп, 13 нче мәктәптә дәресләр уздырырлык мөмкинлек калмагач, безнең 10 нчы классны 8 нче номерлы рус мәктәбенең 10 нчы классына куштылар. Без, 13 нче мәктәптән килүче укучылар, 4 егет һәм 8 кыз булсак, рус классында 18 кыз укучылар бар. Рус кызлары күбесенчә зур гәүдәлеләр, өсләрендә яхшы күлмәкләр, иреннәре һәм кашлары буялган. Татар кызларының киенүләре бик гади, ә аларның каш, ирен буяуларын без күз алдына да китерә алмый идек.

Өлгереш ягыннан да татар укучылары руслардан аерылып торалар иде. Татар мәктәбеннән килгәннәр «яхшы»га укучылар иде. Чөнки «начар» яисә «уртача» билгеләре алып укучыларны, повестка белән чакырып, ФЗО мәктәбенә яисә заводка эшкә җибәреп тордылар. Ләкин безгә рус классында барлык фәннәрне дә рус телендә үзләштерү авыр булып тоелды. Без, татар укучылар, дәрес-ләрдән соң калып бергәләп аңлаша һәм өйгә бирелгән мәсьәлә-ләрне чишә идек.

Химия безнең өчен иң авыр фән булып чыкты. 1938 елга кадәр татарча язуда латин хәрефләре булу һәм химик элементларның язылуы белән әйтелүе бер булу химия фәнен укыганда безгә күп җиңеллек китергән булган. Хәзер исә химик элементларның исем-нәрен русча әйтер алдыннан без тотлыгып тордык. Без, татар укучы-лар, авыр вакытларда бер-беребезгә ярдәм итеп, уңышлы укып бардык.

1943 ел башында әти, югары белемле укытучы буларак, хәрби заводта эшләүдән азат ителде һәм Татарстан мәгариф министрлыгы боерыгы белән Ютазы районына укытучылык эшенә җибәрелде. 1943 елның февраль аенда без гаилә белән Ютазы районына күчеп киттек. Шул районндагы Кәрәкәшле урта мәктәбен мин Мактау грамотасы белән тәмамладым.

## Тагын бер кат Шаммасовлар турында

**«Наша жизнь» район газетасының «Еллар аша…» публикациясендә (7 июнь 2002 ел), Бәрәңгедә егерменче гасырның 30 нчы елларында яшәгән Шаммасовлар гаиләсе турында сөйләнде. Ул публикациягә Аризона штатында (АКШ) улы гаиләсендә яшәгән Нәмикъ Шаммасовның икенче хаты килеп өлгермәгән иде. Анда ул Бәрәңге педучилищесы укытучылары - үзенең әти-әнисе Хәлил һәм Мөсаффа Шаммасовлар һәм шулай ук үзе турында да яңа мәгълүматлар керткән.**

Минем әтием Хәлил Насретдин улы Шаммасов гел кызыксынучан кеше иде, эчкечелекне, тәмәке тартуны бер дә яратмады, һаман белемгә омтылды. Тормышны яхшырак таныр өчен ул 1913, елның апрель аенда эш эзләп Мәскәүгә китә. Мәскәү, Николаев, Херсон шәһәрләренең завод һәм фабрикаларында эшли. Октябрь революциясен ул Мәскәүдә «Гурлянд ширкәте» эшчеләре кол-лективында каршылаган. Аның Самара губернасында халык мәгарифе челтәрендә, аннан сон, Бәрәңгедә эшләү чоры турында мин яздым инде.

«Шомлы елларда» безгә Казанда квартирга ике төн рәттән чекистлар «кара козгында» килделәр һәм төннәр буе зур өстәлнең ашъяулыгы астында сакланган шәхси хатларны укыдылар. Хәтерлим, мин әнигә сыенып урын-жир өстендә утырдым, кара күн пальто кигән чит кешеләрдән куркып йоклый алмадым. Икенче төнгә алар үзләре белән әтине алып киттеләр. Аннары без әни белән әтигә передача ташыдык, ә күрешергә рөхсәт итмәделәр. Әтине елга якын тотканнан соң җибәрделәр. Аның әйтүе буенча, аны милләтчелектә гаепләргә теләгәннәр.

1942 елда безнең абый Наядь фронтка китте, 3 тапкыр яраланып, барлык сугышларны үтеп, Җиңүгә барып җитте. Әтине хезмәт фронтына Зеленодольск шәһәренең №4 заводына, ә әнине армия өчен чаңгы хәзерләүгә эшкә җибәрделәр. 1943 елда, СССР хөкүмәтенең приказын үтәү йөзеннән, әти-әнине хезмәт фронтыннан азат итеп, Татарстанның Ютазы районы мәгариф бүлегенә җибәргәннәр. Алар 1957 елга кадәр, ягъни лаеклы ялга киткәнче, шул районның Кәрәкәшле һәм Бәйрәкә урта мәктәпләрендә укытучы булып эшләделәр.

Ә без, Наядь һәм Нәмикъ, белем алырга беренче адымнарны абый белән Бәрәңгедә ясадык. Әле мәктәптә укыганчы, Наядь абыем дәрес хәзерләгәндә, мин аның янында утырырга ярата идем. Аны тыңлап утырып, укырга һәм язарга өйрәндем. Беренче сыйныфка барганда, инде мин яхшы гына укый, яза һәм саный белә идем. Шуңа күрә мине икенче сыйныфка күчерделәр. Алда да мин бары тик «5»ле билгеләренә генә укыдым һәм урта мәктәпне Мактау грамотасы белән тәмамладым. Укуга игътибарлы булырга һәм аны яратырга мине беренче укытучым Вәлиева Мөнира Глүмовна һәм әти-әнием өйрәттеләр. Күп еллар узуга карамастан, мин Бәрәңге урта мәктәбе укытучыларына, аларның яшь буынны тәрбияләүдә намуслы хезмәтләренә үземнең зур рәхмәтемне белдерәм.

**Н. ШАММАСОВ,**
**хезмәт ветераны, техник фәннәр кандидаты,**
**Аризона штаты, АКШ.**
**Ф. МӨХӘММӘТОВА.**

## Беренче бару

«Аэрофлот» очкычы безне Хабаровскидан Сан-Франциско аэропортына алып килде. Шулай итеп, 1992 елның 20 гыйнварында, иртәнге сәгать 9да без, Нәмикъ белән Наилә, Америка Кушма Штатларына аяк бастык. Безне каршы алырга килгән улыбыз Айрат белән күрештек тә, янә очкычта улыбыз торган шәһәргә - Финикска юл тоттык.

Финикс аэропорты шәһәр уртасында урнашкан. Шундагы гаражда калдырган автомобиленә утыртып, улыбыз безне фатирына алып кайтып китте.

Шәһәр эче булуга карамастан, юлда светофорлар юк. «Фри вей» (ирекле юл) дип аталган махсус тиз йөрү юлы бар, ул һәр якка биш-алты полосалы. Юлдан-юлга күчү исә тимер-бетон күперләр ярдәмендә башкарыла. Без барасы йорт шәһәр эчендәге шәһәрдә - Глендейлда урнашкан икән. Йорт хуҗасы, 80 яшьлек Эвелин ханым, безне ачык йөз белән каршы алды. Эвелинның әти-әнисе бездәге гражданнар сугышы елларында Русиядән күчеп килгән, ә Эвелин үзе Америкада туган, урысча бөтенләй белми.

Бергәләп чәй эчтек тә, Айрат безне бер кунакханәгә илтеп урнаштырды. Америкадагы гадәт буенча, читтән килгән туганнар кунакханәдә яшиләр икән. «Шуңа күрә мин Эвелинга сезне кундыру турында сүз катмадым», - диде улыбыз. Без кунакханәдә аерым апартаментка урнашуыбызга канәгать икәнлегебезне әйттек.

- Иртәгә иртәнге сәгать уннарда Эвелин телефоннан чылтыратыр
да, сезне килеп алып, бер-ике кибет күрсәтер. Бер төрле дә азык-төлек алмагыз, эштән кайтышлый үзем кертеп чыгармын, - дип, Айрат кайтып китте…

Икенче көнне иртән Эвелин, киләсен алдан хәбәр итеп, аннары безне үз автомобиленә утыртып, азык-төлек кибетенә - супер- маркетка алып китте. Бер кварталга сузылган супермаркетка килеп кергәч, ашамлыклар тулы киштәләрне күреп, хәйран калдык. Без Русиядән киткәндә азык-төлек кибетләренең киштәләре буш иде диярлек, калай савытларда бары диңгез кәбестәсе генә тора иде. Ризык тулы киштәләр арасына кергәч, кечкенә арба җитәкләгән Эвелиннан: «Бу хәтле күп продуктны кемнәр алып бетерә соң?» - дип сорадык. Ул, һәр ризыкны кимегән саен өстәп торалар, ә яраклылык вакыты чыкканнарын алыштыралар, дип аңлатты.

Бераз йөргәч, Эвелин менеджер янына кереп чыгам дип киткән иде, озак та тормыйча, менеджер белән бергәләп килеп чыкты. Тегесе, азык-төлек тутырылган зур кәгазь төргәкне безгә биреп:

- Бу- безнең кибет хезмәткәрләреннән сезгә бүләк, - диде.

Чыгу юлына кадәр озатып, кабат үзләренә чакырып калды. Кайткач күрдек: төргәктә туңдырылган тавык ботлары, дөге ярмасы, вермишель, шикәр комы, «Липтон» чәе, кечкенә шешәдә сыек май, ак күмәч һәм бүтән ризыклар бар иде. Без ул ризыкларны берничә көн ашадык.

Американнар бик ачык йөзле кешеләр икән, чит кеше белән дә елмаеп исәнләшәләр. Аваз белән исәнләшкәндә үз ишләренә «һай» дип кенә дәшсәләр, безнең кебек олы яшьтәгеләргә «һеллоу» диләр, «һау ду ю ду» дип тә өстиләр. Без дә исәнләшкәндә, җавап итеп «һеллоу» сүзен кулландык, чөнки «һай» дигәне безгә матур булып тоелмады.

Бер көнне Айратның хезмәттәш дусты, инженер Ральф Гофман безне кунакка чакырды. Юл буе Айрат безгә американнарның кунак каршы алу үзенчәлекләрен сөйләп барды. Нәкь чакырылган вакытка килеп җитә алмаса, кунак телефон аша моны хәбәр итәргә тиеш. Кунак киләсе вакыттан соң 15 минут узса, хуҗа ишекне бикләп куярга мөмкин - моңа хакы бар. Килгән кеше, өйгә кергәч, гадәттә, аяк киемен салмый. Чөнки бу илдә беркем дә җәяү йөрми,ә автомобильдән төшкәч утәсе юл, йорт ишегалды чип-чиста. Американнар башлы-күзле булу белән аерым йортта яшәргә омтылалар һәм шуңа ирешәләр дә. Чөнки эшләүчеләргә банклар кирәк кадәр ссуда бирәләр.

… Ярты сәгать чамасы фри-вейдан килеп, бер катлы коттедж-лар урамына кердек тә, бер йорт каршында туктадык. Монда берничә автомобиль тора иде инде. Тышкы ишектән безне Ральф үзе каршы алды. Елмаеп исәнләште, исәнлек-саулыкны белеште дә: «Американы ошаттыгызмы?» - дип сорады. Гадәттә, американнар исәнләшү белән шул сорауны бирәләр. «Безгә американнарның ачык йөзле булуы, дустанәлеге ошый», - кебегрәк җавап ишеткәч, үз халкы өчен горурлануларын сиздертәләр.

Ральф безне, өенә чакырып кертеп, зал читендәге кухня кебегрәк урынга алып килде. Кухня биредә аерым бер бүлмәдә түгел, ә залдан прилавок-бар өстәле аша гына аерылып тора. Кухняда аш-су әзерләүче ханым - Ральфның тормыш иптәше Жакис белән исәнләштек. Аннары Ральф безгә йортын күрсәтеп йөрде. Йортта өч зур бүлмә бар, икесе - йокы өчен, ә берсе - компьютер бүлмәсе. Йокы бүлмәсенең берсе янында бәдрәф һәм юыну бүлеме (ванна, душ). Ә икенче бәдрәф - коридор ягында, килгән кунаклар шуннан файдалана икән. Йортның арткы ягында бэк-ярд, ягъни кечкенә генә бакча. Бакча уртасында - бассейн, ә бакча тирәли лимон, әфлисун агачлары үсеп утыра. Бакчага урамнан керү капкасы бикле тора. Шул капка белән йорт арасында ике автомобиль сыярлык гараж эшләнгән. Гаражга йорт эченнән дә чыгып

була: ул очракта бер бүлмә аша чыгарга кирәк. Анда исә кер юу машинасы тора. Киштәләрдә төрле хуҗалык кирәк-яраклары. Гомумән, йортның эче дә, тирә-ягы да җыйнак, пөхтә күренә.

«Минем бабаларым Америкага Беренче бөтендөнья сугышы елларында Германиядән килеп урнашканнар», - диде Ральф. Димәк, һәр эштә тәртип, пөхтәлек яратучы алман (нимес) милләтенә хас сыйфатлар үзенә дә ят түгел. Айрат бу хәлгә ачыклык кертте. Гомумән дә, акш халкының күбесен чит илләрдән килгән кешеләр иммигрантлар тәшкил итә икән. һәр иммигрант үзе калдырып киткән илнең гореф-гадәтләрен тотарга тырыша. Бу хәл исә төрле культураларның үзара сыешып яшәвен китереп чыгара. Шуңадыр, күп төрле культуралар бергә җыелган Нью-Йорк шәһәрен кайнап торучы казан - мелтинг пот дип тә атыйлар. АКШ Конституциясе күптөрле-лекнең дуслыгын тәшкил итә.

Шулай әңгәмәләшеп йөргәндә, Жакис безне залга керергә һәм кунак булырга, ризыктан авыз итәргә чакырды. Кухня алдындагы бар өстәлендә төрле кабымлыклар, пешкән тавык, эчемлекләр тезелгән. Бер башта пластмасс тәлинкәләр, стаканнар, кашык-чәнечке-пычаклар салынган тартмалар тора, һәркем тәлинкәләргә үзенә кирәк кадәр азык салып, стаканнарга сулар агызып алып, верандага (патио) чыктык та, өстәл тирәли утырыштык. Шулай ашап-эчеп, гәпләшкәндә, яныбызга бер яшь кенә хатын-кыз килде дә, утырырга рөхсәт сорады. Ул Палестинадан килгән студент кыз Шаһидә икән, монда университетта укый. Безнең мөселман икәнебезне белгәч. Ул дулкынланып китте, шатланды. Киләчәктә Палестина да, күрше-тирәдәге ислам дәүләтләре кебек, ирекле, мөстәкыйль булыр дигән өмет белдерде. Шаһидәгә укуында уңышлар теләдек. Гарәп кызы бүләк итеп биргән медальне - Палестинаның символын әле дә истәлек итеп саклыйбыз.Санаулы көннәр тиз узып китте, бик эчтәлекле булды. Шул арада улыбыз безне Аризона штатының төрек-американ җәмгыяте белән таныштырды. Күп кенә америкалы төрекләр белән күрештек, мәҗлесләреңдә булдык. Җәмгыять җитәкчеләреннән берсе Никки ханым Мурадоглы, автомобиленә утыртып, безне шәһәрнең тирә- ягында йөртеп кайтарды. Җиз мәгъдәне чыгарылган шахта музеен, ковбойлар яши торган трактирлы бистәне, яңа төзелгән госпитальне (соңгысы хатыным Наиләне аеруча кызыксындырды), биш йолдызлы кунакханәләрне һәм башка матур биналарны карадык. Шулай итеп, бер ай эчендә күп яхшы кешеләр белән таныштык. Киләчәктә дә алар белән очрашырга язсын.

Февральнең 20сендә Айрат безне аэропортка илтте һәм без, килгән юл белән, Мәскәүгә очтык. Бу 1992 ел иде. Ә хәзер без АКШта яшәп ятабыз. Бу юлы озаккарак килдек. Хәер, калганын тагы язарбыз эле.

**Наилә һәм Нәмикъ ШАММАСОВлар**.

## Калифорния татарлары җәмгыяте

Америкага чираттагы бер баруда безне Сан-Францискога татарлар җәмгыяте концертына чакырдылар. Җәмгыятьнең идарә әгъзасы Рәкыя ханым Мансур кунакханәгә урнашуда һәм концерт залына керүдә безгә булышлык күрсәтәчәген әйтте. Бу 1995 елның ноябрь ае иде. Без, Феникстан самолет белән ике сәгать чамасы очып, Сан-Франциско аэропортына барып төштек. Улыбыз Айрат вакытлыча кулланып тору өчен аэропот гаражыннан акча түләп җиңел автомобиль алды, безне якындарак урнашкан «Мариотт» кунак-ханәсенә алып килде. Кунакханә бик зур, күпкатлы бинада урнашкан, аның эчке ягы матур итеп җиһазланган. Белешмәләр өстәлендәге хезмәткәр безнең өчен бер номер калдырылуын әйтте. Кунакханә хезмәткәре автомобилебезне капка төбеннән алып гаражга кертеп куйды, кирәк булганда аны үзем китереп куярмын, дип, Айратка автомобиль ачкычын бирде. Айрат кирәкле кәгазьләргә кул куйды да, яныбызга килеп, безне фотога төшерде. (Рәсемдә сез Наилә белән Нәмикъны кунакханә вестибюлендә күрәсез).

Озакламый икенче хезмәткәр безне номерыбызга озатты, ишеген ачып кертеп җибәрде. Номерда ике йокы бүлмәсе, һәр бүлмәдә ике кешелек карават, ике кәнәфи. Залдан ванна бүлмәсенә керү өчен тагын бер ишек бар. Залда зур диван, аның алдында телевизор, телефон. Йокы бүлмәләренең ишекләре дә залга чыга.

Айрат Рәкыя ханымга телефон аша безнең килеп җитүебезне һәм кунакханәгә урнашуыбызны хәбәр итте. Рәкыя ханым концерт буласы клубның адресын һәм бару юлын аңлатты. Сан-Франциско урамнары Феникстагы кебек туры, тигез түгел, шуңа күрә юлга иртәрәк чыгу мәслихәт булыр дип искәртте. Наилә пешергән өчпочмакларны ашап, чәй эчеп, ял итәргә яттык.

Икенче көнне иртән, ашап эчкәч, Айрат безне автомобильдә шәһәр урамнары буйлап алып китте. Бормалы һәм таулы урамнардан бара торгач, океан ярына килеп чыктык. Автомобильдән төштек, диңгез һавасын сулап, дулкыннар шавын тыңлап басып тордык, иелеп, салкын суда кулларыбызны чылатып алдык. Айрат аңлатты: «Мондагы диңгез суы һәрвакыт салкын, хәтта кызу җәй көннәрендә дә җылынмый», - диде. Автомобильгә утырып, юлыбызны дәвам иттек. Ниһаять, кирәкле урынга, концерт буласы клубка барып җиттек. Ишек төбендә безне Рәкыя ханымның улы каршы алды һәм залга кертеп җибәрде. Без залга кергәндә кереш сүзләр әйтелеп беткән, сәхнәдә ике рәт булып баскан мәктәп яшендәге татар балалары Габдулла Тукайның «Туган тел»ен җырлыйлар иде. Җырны без моннан бер ай элек кенә Мәскәү клубында

Илһам Шакиров башкаруында ишеткән булсак та, Америка җирендә татар яшьләре

жырлавына бик куандык. Чөнки җәмгыять эшләрендә яшьләрнең катнашуы, беренчедән, идарәнең яхшы эшләвен күрсәтә, икенчедән, җәмгыятьнең матур киләчәгенә зур өмет тудыра.

Тәнәфес вакытында залда да, вестибюльдә дә татар телендә сөйләшүләр ишетелеп торды. Бусы инде Россиядә яшәүче татарлар өчен дә үрнәк булырлык. Мәскәүдә үтә торган татарча концертларда күбрәк русча сөйләшүләр ишетәсең бит. Рәкыя ханым безнең янга килеп исәнләште, хәл-әхвәл сорашты һәм концерт соңында бергәләп бер мәҗлескә барырга чакырды. Тәнәфес вакытында безнең белән берничә татар егете килеп исәнләште. Алар советлар иленең төрле шәһәрләреннән килгәннәр, математиклар, компьютерчылар икән. Ә бер егет Ютазыдан килгән булып чыкты. Ютазы - Казаннан ерак бер район, 1950 елларда без дә анда яшәгән идек. Шуңа күрә Америка тикле Америкада Ютазы кешесен очрату безгә бик сәер тоелды.

Концертта татарча һәм төрекчә җырлар башкарылды, биючеләр татарча биеделәр. Концерт тулысынча җәмгыятьнең үз көче белән генә әзерләнгән булуга карамастан, без аны канәгатьләнү белән карадык, ошаттык. Концерт бетү белән Рәкыя ханым безнең янга килеп, чыгыш ясаучылар турында фикерләребезне белеште. «Хор да, биючеләр дә, үзләренең ял вакытларын кызганмыйча, бик тырышып әзерлән-гәннәр, без концерттан бик канәгать», - дидек.

Шуннан соң, үз автомобилебезгә утырып, Рәкыя ханымның автомобиле артыннан мәҗлес буласы йортка киттек. Бормалы юллардан ашыкмыйча гына бара торгач, үргә менә торган бер юлга борылдык. Үр башындагы аерым йортларның берсе каршына килеп туктадык. Ул Салих әфәнде белән Шәмсия ханым яши торган йорт булып чыкты. Хуҗалар безне бик шатланып каршы алдылар, табынга утырттылар. Түр башында Сәлих әфәнде белән Шәмсия ханым үзләре урын алды.

Ашау-эчүдән беразга аерылып, барыбыз да өстәлнең бер башынарак җыелдык та, фоторәсемгә төштек. Шул рәсемдә өстәл тирәсенә утырганнар (сулдан уңга) Рифат әфәнде белән Рәшидә ханым Өтүшләр, Салих әфәнде белән Шәмсия ханым Апакайлар, Наилә ханым улы Айрат белән (Нәмикъ артка баскан), Рәкыя Сафа һәм тагын бер ханым. Өстәл түренә басканнар Рәкыя ханым Мансур (ак кофтадан) әнисе (сул ягында) һәм сеңелесе Мәрьям белән. Өстәлнең сул ягында басып торучылар күбесенчә концертта катнашучы яшьләр.

Өстәл янында сүз күбрәк концертны әзерләү турында барды. Чыннан да, шундый зур концертны 100 урынлы тулы залда күрсәтү

өчен оештыручыларның һәм башкаручыларның фидакарь тырыш-лыгы кирәк булгандыр.

Безне шулай ук татарларның Калифорния штатына килеп урнашу һәм җәмгыять оештырып яшәү тарихы да кызыксындырды. Салих әфәнденең аңлатуы буенча, хәзерге вакытта Калифорния штатында, Сан-Францискода яшәүче татарларның күбесе төрле елларда Россиядән Маньчжуриягә, Япониягә һәм Төркиягә киткән татарларның балалары яисә оныклары. Аларның биредә җәмгыять оештыру язмалары Халидә ханым Деушта сакланган булырга мөмкин икән. Шулай ук һәр гаиләнең кызыксыну тудырырлык үз тарихы бар, дип тә өстәде Салих әфәнде.

Өстәл яныннан кузгалгач, без пианино янына килеп, кумәкләп татарча җырлар җырладык. Шәмсия ханым белән Наиләнең Г. Тукай сүзләренә «Тәфтиләү»не җырлавы барыбызга да ошады. Соңыннан бер очрашуда Халидә ханым безне Сан-Франциско татар җәмгыяте оештыру турында түбәндәге мәгълүматлар белән таныштырды.

Сан-Францискода 1924 елда беренче булып урнашканнардан Хәсән әфәнде Салихов гаиләсен, Мотыйгулла Гарифуллин гаиләсен һәм Габдулла әфәнде Зәйнәшевне әйтергә була. Алар үзара йөрешеп, күрешеп яшиләр һәм яңа килгән татарларны үзләренә якынлаштыралар. Шулай сөйләшуләр вакытында татарларны бер-ләштерүче оешма төзү зарурлыгы ачыклана.

1960 елда беренче кумәк җыелышта оешма төзү турында карар кабул ителә. Аның рәсми исемен «Америка Төрки-Татар оешмасы» дип куярга булалар. Оешманың төп бурычы итеп дини-мәдәни һәм җәмгыятькә караган эшләрне башкару билгеләнә. Киңәшле эш таркалмас диләр бит, оешманың тормышын киңәшле рәвештә алып бару өчен идарә сайлап куела. Беренче идарәгә 9 кеше керә: Заһидулла Агиш - рәис, Сәгыйд Килки - рәис урынбасары, Рәшит Акчурин, Рәбига Биги, Рауза Рогард, Мәхмүд Деуш, Ф.Газизов, Йосыф Дикаприо, Рәбига Әгерҗе - идарә әгъзалары. Шул вакытта Калифорния хөкүмәте татарларның дини-мәдәни оешмасын этник төркем буларак рәсми рәвештә таный һәм һәртөрле салымнардан азат итүен белдерә.

Идарә җәмгыять эшләрен башкаруда җаваплы кешеләрне билгели, бер бина сатып алу һәм төзекләндерү эшләрен башкара.

Мәктәп яшендәге балалар өчен татар телендә дин дәресләре ачыла. Дәресләрне Тасия ханым Килки һәм Шәмсия ханым Апакай уңышлы алып баралар. Ханымнар бүлекчәсе, яшьләр түгәрәге аерым-аерым яисә бергәләшеп бәйрәмнәрне күңелле итеп үткәрү, татарча пьесаларны сәхнәгә кую, башка төр массакүләм агарту эшләрен оештыралар. Бу эшләрдә Салих әфәнде белән Шәмсия ханым

Апакайлар, Халидә ханым Деуш, Рауза Рогард, Рәкыя Мансур, Нәркис Гелинг һәм башкалар даими рәвештә актив катнашалар.

Калифорния татар җәмгыятенең тарихы язылырга, дөнья күрергә тиеш. Бу юнәлештә Муаззиз Байбулатның «Тампере ислам җәмгыяте: нигезе һәм тарихы» (Финляндия) дигән тирән эчтәлекле, күп иллюстрацияле китабы үрнәк булып тора.

## Монда да татар эзе

Америкада яшәү өчен беренче чиратта инглиз телен әйбәт белү кирәк. Яшьләр инглиз телен мәктәпләрдә, колледжларда, университетларда өйрәнәләр. Безнең кебек чит илдән килгән пенсия яшендәгеләр, бертөрле дә акча кереме булмаган кешеләр аерым курсларда укыйлар. Без, ирле-хатынлы ике пенсионер, шул курсларның берсенә йөри башладык. Анда инглиз телен өйрәнүчеләргә башлангыч мәгълүматлар бирәләр, ә телне яхшыртырга теләүчеләргә өстәмә ярдәм күрсәтелә. һәрбер укучының өстәлендә компьютер бар. Дәресләрне ирекле укытучылар - волонтирлар алып бара. Укытучылар барысы да югары белемлеләр, эш хакы алмыйча, үз инициативалары белән эшлиләр. Ике ай шул курсларда укыганнан соң безгә, әби белән бабайга, укуларны туктатырга туры килде, чөнки өйдә оныгыбыз Рәшидне карашып, гел аның янында булырга кирәк иде.

Безнең хәлне белгәч, бер укытучы-волонтир - мисс Маргарет безгә өйгә килеп дәрес биреп йөрергә ризалыгын белдерде. Бу хәбәрне шатланып каршы алдык. Маргаретның дәресләре атнага ике мәртәбә безнең йортта узды. Дәресне Рәшиднең йоклаган вакытына туры китердек. һәр дәрескә Маргарет, үз машинасына утырып, кирәкле әсбапларны алып йөри башлады. Дәресләр вакытында Маргарет үзе турында да күпмедер мәгълүмат бирде.

Ул университетта тарихчы белемен алган. Хәзер пенсиядә. Үз башлангычы белән шәһәр музеенда экскурсовод булып һәм курсларда инглиз теле укытучысы булып эшли. Маргарет Феникс шәһәренең Скотсдейл исемле байлар районында үз йортында яши. Мәгълүм ки, Сталинның кызы Светлана Аллилуева да соңгы елларын Скотстдейлда яшәгән һәм шунда күмелгән.

Маргаретның үз балалары үсеп-җитеп, гаиләләре белән Американың төрле шәһәрләрендә, кайберсе чит илләрдә яшиләр. Ул ай саен Калифорниядә яшәүче улының гаиләсе янына барып кайта. Тиздән Австралиягә һәм Яңа Зеландиягә кызлары янына барырга

җыена.

Тарихчы буларак, Маргарет безгә җирле американнар яшәгән урыннарны күрсәтергә теләде. 2002 елның 12 апрелендә Маргарет үзенең бик уңайлы «Тойота» маркалы автомобилендә безне Ферикстан төньякка таба алып китте. Популяр әдәбиятта Америка магистраль автомобиль юлларының төзек һәм юлчылар өчен уңайлы булуы турында куп язылган. Чыннан да, без бу күренешләрнең барысына да шаһит булдык. Юллар киң, һәр юнәлештә 3-4 рәт билгеләнгән. Каршы юнәлешкә күчүне төрле биеклектәге бетон күперләр ярдәмендә башкарып була. Юлларның автомобильләр йөри торган өлеше генә түгел, ә тирә-ягы да чиста. Юл билгеләре бик ачык күренеп торалар. Юл кырыенда җиһазландырылган ял итү урыннары бар. Анда юлчыларны канәгатьләндерерлек барлык шартлар тудырылган. Витринада юл картасы эленгән, телефон-автомат эшли, телефон китабының битләре, ертылу түгел, хәтта тапланмаган да. Ашау-эчү урыннары өстәл-урындыклары белән түбә астында урнашкан. Чиста бәдрәфтә хуш исле сабыннар, салкын һәм кайнар сулы раковиналар тора, кәгазь сөлгеләр эленгән. Шунысы безнең өчен гаҗәп булды: бар җиһазлар да төзек, чиста килеш тора, бер нәрсә дә ватылмаган, пычранмаган. Ә бит ял урынына күп кеше кереп чыга. Бару юлында туктап ял иткәндә Маргарет борынгы американнарның тормышы турында кызыклы мәгълүматлар сөйләде һәм безгә иллюстрацияле китаплар да бүләк итте. Ике сәгатьтән без Седана шәһәренә барып җиттек һәм, магистраль юлдан төшеп, таш җәйгән юл буйлап таулар арасына кереп киттек (рәсемдә - Седана тирәсендәге таулар). 10 миль (16 км) араны узгач, машина белән юлдан читкә төшеп, зур таштау итәгендә куелган киртәле капка янында туктадык. Витриналардагы мәгълүматларны, экскурсия маршрутын укый башлагач, безнең янга бер яшь ир килеп, үзен гид дип таныштырды һәм ярдәмен тәкъдим итте. Без гид артыннан бормалы сукмак белән әкрен генә тауга менеп киттек. 30 метр биеклеккә менгәч, бер зур куыш алдында тукталдык. Ул куыш тау эченә 4-5 метрга кергән, тигез горизонталь идәне бар. Гомумән, куыш хәзерге парклардагы җәйге эстрада сәхнәсенә охшаган. Бу турыда гидка әйткәч, ул күкрәгенең эчке кесәсеннән курайга охшаш бер агач уен коралы алды да өреп уйный башлады.

Ул уйнаган көй татар халык көенә исткиткеч охшаган иде. Шул вакытта тирә-якта кошлар тавышлары тынды һәм йомшак кына җил исә башлады. Гид уйнаудан туктагач кошлар сайраша, шаулый башладылар, ә җил басылды. Табигатьнең нигә шулай тиз үзгәреп алуын без аңлый алмадык. Аризона штатының географик картасында Хавасу исемле күл һәм шәһәр дә бар икәнен белдек. Кызык бит,

татарчага охшап тора - һава һәм су…

Җирле американнар арасында татарларның (төркиләр) булуы Маргарет биргән популяр китапларны укыгач аңлашылды. Колумб Америка кыйтгасын ачканчы күпкә элегрәк, Төньяк Американың көнбатыш өлешенә Себердә яшәүче кешеләр килгәннәр. Америкада басылган географик карталар буенча исә Себер - татарлар иле. Шуңа күрә, җирле төп американнар арасында төрки теллеләр - татарлар күп булуы ачыклана. Аларның Себердән күчеп килүләрен Америка тарихчылары болай аңлата. Моннан меңнәрчә еллар элек Беринг бугазы бик тар булган, Себер ягындагы кешеләр көймә белән Америка материгына чыга алганнар һәм күчә-күчә кыйтгага таралганнар. Алар калдырган аучы әсбапларын, каберләрен Америка археологлары бүген дә табалар. 8 мең ел элек Беринг бугазында су күтәрелеп, аның иң тар җирендә киңлеге 100 километрга җиткәч, Себердән күпләп күчү тукталган. Америкада төпләнеп калган кабиләләрнең 2000 төрле телләре һәм диалектлары бар. Америка археологлары төп американнарның мәдәниятен һәм күршеләре белән булган элемтәләрен ачыклау ниятеннән фәнни тикшеренүләрне дәвам итәләр.

**Наилә һәм Нәмикъ**
**ШАММАСОВЛАР.**
**Феникс, Аризона штаты. АКШ.**

## Безнекеләр Япониядә

Икенче Бөтендөнья сугышы тәмамланып килә. Европада Германия гаскәрләре капитуляция игълан итә. Ләкин Япония гаскәрләре сугышны дәвам итәләр. Американың хәрби очкычлары эзлекле рәвештә япон шәһәрләрен бомбага тота.

1945 елның июнь аенда Япониянең Кобе шәһәрен дә бомбага тоту башлана. Шәһәр уртасында урнашкан мәһабәт мәчет ут эчендә кала. Ләкин имамның алдан үк күргән чаралары һәм япон солдатларының саклавы нәтиҗәсендә, мәчет эченә ут керми һәм җиһазлар янмый. Америка очучыларының да, Ходай кушып булса кирәк, бомбалары мәчеттән читкәрәк төшә. Бомбалау тукталып, Америка очкычлары очып киткәч, мәһабәт мәчет җимерек шәһәр биналары уртасында ялгызы басып кала (сурәттә - Кобе мәчете бомбалаудан соң). Озакламый икенче Бөтендөнья сугышы тәмамлана. Татар мәхәлләсе әгъзалары үз көчләре белән мәчетнең тышкы ягын төзекләндерәләр (Кобе мәчетенең хәзерге сурәтенә игътибар итегез). Шулай итеп, мәчет 1935 елда Согуд Гарәбстаны ярдәмендә

төзелгән хәленә кайта.

Мәчетнең имамы булып озак вакытлар Хөсәен Абдулгалим улы Килки хезмәт иткән. Ул Пенза губернасы Юни шәһәрендә туып-үскән, беренче Бөтендөнья сугышында яраланып кайткан, соңыннан Гарәбстан мәдрәсәләрендә имамлыкка укыган кеше. Хөсәен әфәнде татарча, урысча, гарәпчә, инглиз һәм япон телләрендә укый-яза белгән һәм сөйләшкән.

Кобеда имам һәм мәхәллә рәисе буларак, Хөсәен Килки мәгърифәт өлкәсендә дә зур эшчәнлек күрсәткән. Мәчет күршесендә ул татар мәдрәсәсе ачкан. Анда Коръән, дин тарихы, ана теле, милли тарих, җәгърафия, табигать, хисап, инглиз теле, япон теле, рәсем кебек дәресләр бирелгән. Мәдрәсәгә имам Төркиядән, Гарәбстаннан, Маньчжуриядән тәҗрибәле мөгаллимнәр чакырткан.

Күренекле мәгърифәтчеләр Гимадетдин Баймөхәммәди һәм Рабига Дәвеш Газизова, читтән килеп, Кобе мәдрәсәсендә мөгаллимнәр булып эшләгәннәр.

Уку-укыту эшләрендә Хөсәен әфәнденең кызы Халидә ханым Дәвеш тә катнашкан.

Мәдрәсәдә укып чыккан шәкертләрнең инглиз һәм япон телләрен белүләре аларның киләчәк тормышында ярдәм иткән, сугыштан соң ачылган Америка офисларында эшләргә мөмкинлек биргән.

Имам Хөсәен Килки, халык алдында бик зур ихтирам казанып, 41 ел имамлыкта торганнан соң, 1993 елда вафат була. Мәхәллә әгъзалары җыелышып, аның каберенә таш куйдыралар.

Аның улы Фәрид Килки - гаиләсе белән хәзер дә Кобеда яши һәм мәчеттә мөтәвәллият эшләрен башкара.

Кызы Халидә ханым Килки Дәвеш хәзер Америкада, Сан-Франциско шәһәрендә кызының гаиләсендә яши һәм Сан-Франциско татар җәмгыяте эшендә актив катнаша.

Халидә ханым Килки Дәвеш үз җәмгыятьләре турында болай дип яза:

«Без хәзергә кадәр төрле мәмләкәтләрдә яшәп килдек. Ләкин динебез, телебез, гореф-гадәтләребезне онытмыйча, бергә-бергә кайнап яшибез. Яшьләребезгә дә шул юлны күрсәтеп киләбез. Киләчәктә дә шулай яшәсеннәр дип телибез. Амин.»

Бу язмамда китергән мәгълүматларны да мин Халидә ханым истәлекләреннән алдым (ул аларны язып барган).

Рәсемнәрдә: Кобе шәһәре мәчетенең сугыш ахырында, шәһәр бомбага тотылгач төшерелгән bәм бүгенге күренешләре. Имам Хөсәен Абдулгалим улы Килки. Япониядә - татар балалары (сугыштан соңгы еллар).

**Нәмикъ Шаммасов.**
**АКШ, Феникс шәһәре.**

P.S. Нәмикъ абыйның язмасына өстәп, АКШтан электрон почта аша «Т.Я.»га сурәтләр җибәргәннәре өчен Халидә ханым Килки-Дәвешкә һәм Җүнәт Җапануглыга рәхмәт белдерәбез.

**Мөхәммәтсафа хәзрәт кызы**

«Мәгърифәт» газетасының 2007 елның 17 февралендә чыккан 7нче санында Рәшит Сираҗиевның «Мөхәммәтсафа хәзрәт кабызган йолдыз» исемле мәкаләсе чыккан, анда имам-мулла Мөхәммәтсафа Биккенин турында күп мәгълүматлар тупланган. Без аны зур канәгатьләнү белән укыдык, Биккениннар нәселеннән булган кешеләр белән үзебезнең очрашуларыбызны искә алдык. Шуларның кайберләрен кәгазьгә дә төшердек. Андый күркәм кешеләр татар милләте тарихында күренекле урын алырга лаек.

1953 елның август аенда мин, ул чагында Уфа нефть институты студенты, Уфа авыл хуҗалыгы институты студенты Рәшит Биккенин белән икәү Бәйрәкәгә каникулга кайттык. Юлда Рәшит кыскача гына үзләренең гаиләсе турында сөйләде. Әти-әниләре репрессиягә эләккән икән, үзе балалар колониясендә булып, алдагы елда гына азат ителгән. Бәйрәкә больницасында аның апасы врач булып эшли, шул Рәшитне кунакка чакырган икән. Минем әти белән әни Бәйрәкә урта мәктәбендә укыталар иде.

Авылда печән әзерләү, бакча карашу кебек эшләрдә без Рәшит белән бергәләп катнаштык, җиләккә дә йөрдек, өмәләрдә дә эшләдек. Ул бик ачык, эчкерсез кеше, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер, үзенә авырлык килгәндә зарлануны белә торган түгел иде. Рәшитнең апасы Мәсхүдә Сафовна турында мин соңыннан, еллар үткәч кенә хатыным Наилә Идрисова-Шаммасовадан белештем.

1952 елда Наилә, Ютазыда район сәламәтлек саклау бүлеге мөдире булып эшли башлагач, Бәйрәкәгә участок больницасына килгән, баш табиб Мәсхүдә Сафовна белән танышкан. Тәҗрибәле белгеч буларак, Мәсхүдә Сафовна эшен яхшы башкарган, халык арасында абруе зур булган. Эшләү дәверендә Наилә аның белән еш очрашып торган. 1956 елда Наилә Ютазы районыннан күчеп киткән, Мәсхүдә Мөхәммәтсафа кызы белән башка очрашмаган.

**Еллар аша…**

**«Наша жизнь» газетасының 2001 ел 20 апрель санында чыккан, Бәрәңге педучилищесы тарихына багышланган «Биредә укытучылар әзерләгәннәр» дигән язма уңаеннан анда укыган кешеләрдән, укытучыларыннан байтак хәбәрләр алынды.**

**Аларның соңгысы …Америка Кушма Штатларыннан, Аризона штатыннан Нәмикъ Хәлил улы Шаммасовтан килде.**

## Фоторәсемдә әти-әниемне таныдым

«Хөрмәтле редакция! Сезнең газетада 2001 елның 20 апрелендә Бәрәңге педтехникумының тарихы турында «Биредә укытучылар әзерләгәннәр» дигән мәкаләне дулкынланып укыдым. Автор һәр вакыйганы анда катнашучыларның конкрет фамилияләрен күрсәтеп тасвирлый яки күмәк фоторәсемнәр китерә. Педтехникум коллективының 1934 елгы фоторәсемендә минем әти-әнием Шаммасовлар да бар: беренче рәттә уртада әтием Хәлил Насретдин улы утыра, икенче рәттә ак кофтадан, сулдан бишенче - әнием Мөсәффә Абдулла кызы. Шундый фоторәсем безнең гаилә альбомында да саклана иде, ләкин, кызганычка каршы, ул миндә юк.

1936 елда безнең гаилә Бәрәңгедән Казанга кайтып китте. Бәрәңгедәге хәвефле еллар турында әти-әниләрем Бәрәңге педтехникумында укып чыккан ике егеттән (исемнәрен белмим) ишетте, алар Казанда берничә көн бездә торганнар иде. Егетләр педтехникум укытучылары һәм студентлары арасында кулга алулар турында сөйләделәр. Репрессияләр Казанда да булды, әмма без бу хәлләр Бәрәңгедә дә булгандыр дип уйламаган идек. Репрессияләр минем әтине дә, башка туганнарны да читләтеп үтмәде.

Әти белән әни Бәрәңге педтехникумында 1934-1936 елларда эшләделәр, ә педагогик эшчәнлекләре күп элек башланган иде.

## Укытучы Шаммасовлар

Хәлил Насретдин улы Шаммасов укытучылар династиясеннән. Аның әтисе Насретдин Шәмсетдин улы Шаммасов 1850 елларда Казанда мәдрәсәдә укыган, шул ук вакытта Шиһабетдин Мәрҗанидән дә сабаклар алган, аның мәчетенә намазга йөргән. Самара өязенең Карга Куак, Иске Фәйзулла авылларында хәлфәлек иткән. Дин әһеле буларак, татарча гына түгел, гарәпчә, төрекчә дә укый белгән, шул чакта чыккан әдәби журналларны алдырган.

Насретдин ишле гаилә башы булып, уллары Самара, Оренбург, Мәләкәс мәдрәсәләрендә укыган.

Улларыннан берсе Хәлил Шаммасов Мәләкәс мәдрәсәсендә (Казаннан ерак түгел) белем алган. 1912 елда ул беренче тапкыр Самара өязенең Яңа Фәйзулла авылына мөгаллим булып килгән. Мөгаллимлек эшендәге беренче адымнары турында болай дип язып калдырган: «Мин килгәннең икенче көнендә авыл мулласы, мәчеттән җомга намазыннан чыгып килүче мәхәллә кешеләрен туктатып, болай дип сүз кушты: »Җәмәгать, безгә мөгаллим килде. Сабакка йөрергә тиешле балаларны ачыкларга, мөгаллимгә эш хакы билгеләргә кирәк. Шушы мәсьәләне ничек хәл итәбез?» Картлардан берсе, аптырашка калып, болай диде: «Акча түли торган нинди эш ди ул? Без акча каян алыйк? Атнага бер тапкыр сәдака бирербез, урнашырга ярдәм итәрбез. Моңарчы элекке мөгаллим белән шулай яшәдек бит әле».

Әмма яшьрәкләр мулланы яклап чыктылар, кышкылыкта һәр укучы өчен 50шәр тиен түләргә карар иттеләр: «Яшәвен мәктәптә яшәр, ачка үтермәбез», - диделәр.

2-3 көн эчендә укырга 80ләп бала язылды. Аларны белемнәренә карап өч сыйныфка бүлдем, ике сменада укытырга булдым. Мәктәптәге җиһазлар тезләнеп укый торган 3-4 партадан, бәләкәй генә бер шкафтан гыйбарәт иде. Укытучылык эшемне мин шулай башлап җибәрдем».

Заман Хәлил белән Мөсәффәдән югары белем алуны таләп итә. Хәлил Казан университетының физика-математика факультетын тәмамлауга ирешә, Мөсәффә Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияте факультетында укып чыга.
Тормыш юллары Хәлил белән Мөсәффәне Бәрәңгегә китереп чыгара, анда алар педучилищеның иң беренче югары белемле укытучыларыннан булалар.

Ә без, аларның уллары Наяд белән Нәмикъ, Бәрәңге мәктәбенең башлангыч сыйныфларында мәгърифәт юлындагы беренче адымнарыбызны ясадык, энебез Марат әле мәктәп яшенә җитмәгән иде.

1936 елда Шаммасовлар Бәрәңгедән киттеләр. Алар бөтен гомерләрен балаларга аң-белем бирүгә багышладылар, озак еллар урта мәктәптә эшләделәр. Мөсәффә Шаммасова «Татарстан АССРның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Хәлил белән Мөсәффә 1957 елда лаеклы ялга чыктылар, минем гаиләм белән бергә Әлмәттә яшәделәр. Әни 1983 елда, әти 1990 елда вафат булдылар. Аларның уллары, без өчебез дә әти-әниебез

эшен дәвам иттек. Наядь - техник фәннәр кандидаты, Уфа нефть институтында укытты, мин - Нәмикъ, шулай ук техник фәннәр кандидаты, доцент, Казанда төзүче инженерлар институтында укыттым. Ә Марат педагогия институтын тәмамлады, Җәлил бистәсендә урта мәктәптә укытты. Хәзер өчебез дә лаеклы ялда, балаларыбыз, оныкларыбыз белән яшибез.

Бәрәңгедә Шаммасовлар фамилиясен онытмауларына бик шатландык, әти белән әни Бәрәңгене беркайчан да онытмадылар. Без үзебез дә анда белем юлына алып кергән укытучыларыбызга һәрвакыт рәхмәтле. Бәрәңге кешеләренә тазалык, уңышлар, киләчәккә ышаныч белән яшәүләрен телибез.

## Гомерлеккә күңелемә кереп калдылар

Нәмикъ Шаммасовның шушы хатын һәм инде Америкадан җибәргән фоторәсемен (Нәмикъ Шаммасов хатыны Наилә һәм оныгы Рәшит белән төшкән) алып мин Садриева Роза Абдулла кызы янына юнәлдем. Педтехникумның беренче укытучылары арасында аларның исемен телгә алучы шул кеше иде бит. Фоторәсемгә карау белән Роза Абдулловна болай диде: «Нәмикъ бала чагында ук этисенә ошаган иде, хәзер тач үзе - Хәлил Насретдинович булган икән».

- Нәмикъ Америкага ничек барып чыккан соң? - Роза Абдулловнаның соравы бик табигый иде.

- Кече улы Айрат Мәскәүдә укыган, Россия-Америка уртак фирмасында эшләгән, шуннан аны АКШка чакырганнар, үзе белән бергә эти-әниләрен дә алып киткән, - дип аңлаттым мин.

- Ә безнең газета аларга ничек барып эләккән?

- Бик гади генә. Дөнья тар, җир түгәрәк, диләр бит. Айрат Бәрәңге РКЦы башлыгы Равия Әхмәтвәли кызы Фәйзрахманованың туганнарының кызына өйләнгән. Татарстанда аларның туйларында Бәрәңге турында, педучилище турында да сүз чыккан. Бераздан шунда газетаны да җибәргәннәр. Ә сез Шаммасовларны хәтерлисезме соң әле? - дип сорадым мин.

- Ә минем аларны онытканым да юк, - дип җавап бирде Роза Абдулловна. - Миңа училищеда татар теле һәм әдәбияте укытучы, бу предметка мәхәббәт тудыручы шул Мөсәффә Абдулловна булды бит инде. Аннары үзем дә Казан педагогия институтының татар бүлеген тәмамладым, район мәктәпләрендә, педучилищеда 43 ел укыттым, «Мари АССРның атказанган укытучысы» исемен алдым.

- Бу гаилә минем күңелемә гомерлеккә кереп калды, - дип

дәвам итте ул сүзен. - Алар Бәрәңгегә 1934 елны җәй көне килгәннәр иде. Карл Маркс урамының көньяк очында, без фатирга кергән йорттан 2-3 өй аша гына урнаштылар. Педучилищега барганда мин көн саен аларның өе кырыеннан үтә идем. Малайларын да хәтерлим,

бик зиһенле, шаян, ләкин тәрбияле малайлар иде. Исемнәре генә безнең өчен ничектер ят. «Ничек инде шундый әйбәт малайга Нәмикь дигән сәер исем куштылар икән?» - дип уйлый идем. Ишек алдын җыештыру, монда килү белән базарда сатып алган кәҗәләрен карау Наядь белән Нәмикь өстендә иде.

Хәлил Насретдинович белән Мөсаффа Абдулловна ходай сәләт биргән укытучылар иде. Укыту процессына алар күп яңалыклар керттеләр. Хәлил абый математикадан укыта, Мөсәффә апа татар теленнән тыш географияне дә алып бара иде. Аларның дәресләрен без көтеп ала торган идек. Үзләре бик культуралы, тыйнак итеп, зәвык белән киенәләр. Студентлар һәр көнне Мөсәффә Абдуловна бүген ни киеп килер икән дип көтәләр иде. Өйләрендә китаплар, газета-журналлар күп булды. Без яраткан укытучыларыбызга еш барабыз, капка төбендәге эскәмиядә газета-журналлар карыйбыз, китаплар укыйбыз, алар исә безнең уку дәртенә шатланып торалар иде.

Ул елларда педучилищеда фатыйма Гатауллина (татар теле), Иванов (мари теле), М.Н. Лежнина (рус теле), яшь математик Кондаков, А.Н. Петухов укыттылар. Югары белемнәре булмаса да, районда мәгарифне үстерүгә зур өлеш керттеләр. Ирле-хатынлы Шаммасовлар алар өчен педагогик осталык үрнәге булып торалар иде. Тик алар 1936 елда китеп бардылар. Ни сәбәптән икәнен без белмәдек, шул хәвефле, болгавыр еллар аркасындадыр инде дип уйладык. Истәлеккә шушы 1934 елда укытучылар белән укучылар бергә төшкән фоторәсем генә калды. Анда мин икенче рәттә сулдан беренче булып кара берет киеп утырам. Ә беренче рәттә утырган укытучы Каюм Бигәшевнең йөзе танымаслык итеп буялган. Ул 1938 елда «халык дошманы» дип атылды, андый кешеләрнең фоторәсемен калдырырга да ярамый, шундый усал заманнар иде бит.

1937 елның июлендә мин Ижевскига әниемнең туганнарына бара идем. Казанда һич көтмәгәндә Бәрәңге мәктәбе укытучысы Наҗия апа Бигәшеваны очраттым. Ире «халык дошманы» дип кулга алынганнан соң улы янына Урта Азиягә барышы икән. Наҗия апа мине Кабан күле буенда ул чакта Шаммасовлар торган йортка алып барды. Хуҗалар безне туганнары кебек якын итеп каршы алдылар. Ә малайларның күңелләре күтәренке, үзләре элеккечә шаян иде, Казанда яшәү ошый торгандыр инде. Шаммасовлар белән мин бүтән

очрашмадым. Әмма чын педагоглар, кеше җанын тәрбияләүчеләр буларак аларга һәрвакыт мәхәббәт һәм ихтирам саклап яшәдем. Аларның балалары да үзләре кебек акыллы, белемле булып үсүләренә бер дә аптырарлык түгел, эти-әниләрен истә тотуларына мин бик шат. Мөмкин булса, аларга хат та язар идем әле, - дип тәмамлады Роза Абдулловна сүзен.

- Бу заманда бөтен нәрсә дә мөмкин, - дидем мин. - Хәзер хәтта интернет аша да язышып торалар, эти-әниләренең фоторәсемен миңа шул интернет аша җибәргәннәр бит. Гади хат язып салганда да барып җитәчәк.

Роза Абдулловнага инде 83 яшь, бу кышта саулыгы бик шәптән булмаган.

- Нәмикъ Шаммасовның хаты мине яшьлегемә алып кайтты, яңа тормыш биргәндәй булды. Рәхмәт аңа, - диде апабыз.

Безнең Бәрәңгене яхшы яктан искә алган өчен Шаммасовларга бездән дә рәхмәт.

**Ф. Мөхәммәтова.**

## Мөгаллим Шаммасовлар

**Редакциягә Җир шарының теге ягыннан - Американың Феникс шәһәрендә яшәүче техник фәннәр докторы Нәмикъ Шаммасовтан хат килеп төште. Торган җире ерак булса да, әлеге милләттәшебез укучыларга яхшы таныш. Хәтерләсәгез, моннан беркадәр элек без аның элеккеге елларда Казан күле бозында ел саен үтә торган алышлар, кул сугышлары хакындагы истәлекләрен сезнең игътибарга тәкъдим иткән идек. Инде менә Нәмикъ ага үз нәселендәге мөгаллимнәр белән дә тирәнрәк таныштыра.**

1912 елның көзе. Ульян өлкәсенең Яңа Фәйзулла авылы мулласы җомга намазыннан чыккан халыкка яңа хәбәр җиткерә.

- Җәмәгать, - ди ул, - безнең авылга яшь мөгаллим килде. Аның исеме Хәлил Шаммас. Мәләкәс мәдрәсәсендә җәдид ысулында укып, медәррис Гатаулла хәзрәт кулыннан афәрин (мактау кәгазе) алган. Мәдрәсәдә укудан тыш, русча укырга-язарга өйрәнгән. Аның атасы Хуҗа Насретдин Шаммас сезгә билгеле дин әһеле. Хәзер безгә, балаларны хисапка алып, мөгаллимгә жалование билгеләргә кирәк булыр. Бу мәсьәләне ничек хәл итәбез?

Шулчак халык арасыннан бер карт: «Ул нинди эш «жалуния» бирерлек? Без кайдан алыйк ул акчаны? Без аңарга атна кичләрендә

сәдака бирербез, үзен тәрбия итәрбез. Әлегә кадәр булган мөгаллим дә шулай торды бит әле», - диеп караса да, яшьрәкләр мулланың сүзен куәтлиләр. Фикер алышулардан соң, бер кышка һәр укучыдан 50 тиен акча түләргә, дип карар кылына.

Ике-өч көн эчендә укырга 80 ләп бала языла. Алар белемнәренә карап өч сыйныфка бүленә. Дәресләр ике сменада оештырыла. Мәктәпнең барлык җиһазы тезләнеп укырлык 3-4 партадан, укытучы өстәленнән һәм кечкенә генә бер шкафтан гыйбарәт була.

Хәлил Шаммасов укытучы эшен яратып башкара. Ләкин егетнең яшь күңеле дөнья күрергә, зуррак җирләргә ашкына һәм ул гади эшче булып Мәскәү, Николаев, Херсон фабрикаларында эшли. Октябрь революциясен ул Мәскәүдә «Товарищество Гирлянд» фабрикасында каршы ала.

1918 елда ул, Самарага кайтып, укытучылар әзерләү курсларында укый, соңыннан Самара өязенең татар мәктәпләре инспекторы, ә 1920 елдан Татар-Башкорт техникумында (Самара) укытучы булып эшли.

1921 елда Хәлил Шаммасов авыл укытучысы Мөсаффа Гыйльметдиновага өйләнә. 1923 елда алар Казанга күчеп киләләр. Хәлил Татнаркомфинда инспектор булып эшли һәм Казан университетының физика-математика факультетында читтән торып укый.

Ләкин сәяси репрессияләр Шаммасовлар гаиләсенә дә кагыла. 1933 елда НКВД агентлары төнлә килеп фатирда тентү ясыйлар һәм Хәлилне кулга алалар. Бер ел Пләтән төрмәсендә тотканнан соң ул иреккә чыгарыла. Ләкин 2 ел дәвамында Казанда тору хокукыннан мәхрүм ителә. Шаммасовлар Бәрәңге авылында (Мари Иле республикасы) яңа ачылган педтехникумда укыта башлыйлар. Югары белемле һәм тәҗрибәле укытучылар буларак коллективта абруй казаналар. Шул вакытта студент булган, ә хәзер үзе дә Мари Республикасының атказанган укытучысы Роза Габдулла кызы Садриева болай дип искә ала: «Хәлил Насретдинович һәм Мөсаффа Габдулловна - Ходайдан бирелгән сәләтле укытучылар. Алар укыту процессларына күп яңалык керттеләр, аларның дәресләрен без, студентлар, түземсезлек белән көтеп ала идек».

1936 елда Шаммасовлар Казанга кайталар һәм татар мәктәпләрендә укытуларын дәвам иттерәләр.

Ватан сугышы башлану белән Хәлил, хезмәт фронтына алынып, Яшел Үзән шәһәрендәге заводка эшче итеп җибәрелә, ә Мосаффа армия өчен чаңгылар ясый торган фабрикада эшли. Бу вакытта олы уллары Наядь тә фронтка китә.

1943 елның февралендә хөкүмәт карары нигезендә Хәлил һәм Мөсаффа хәрби предприятиеләрдән чакырып алыналар һәм

Татарстанның Ютазы районына укытучы итеп җибәреләләр. Алар Кәрәкәшле һәм Бәйрәкә урта мәктәпләрендә пенсиягә киткәнче, ягъни 1957 елга кадәр эшлиләр. Мосаффа Шаммасова «Татарстанның атказанган укытучысы» исеменә лаек булды.

Хәлил һәм Мөсаффа, 1957 елда пенсиягә чыгып, безнең (уллары Нәмикъ гаиләсе) белән бергә Әлмәттә яшәделәр. Мосаффа 1983 елда, Хәлил 1990 елда вафат булды. Аларның өч уллары да, югары белем алып, укытучы эшен дәвам иттеләр. Наядь - техник фәннәр кандидаты, доцент, кафедра мөдире булып Уфа нефть институтында, Нәмикъ - техник фәннәр кандидаты, доцент булып Казан төзелеш инженерлары институтында эшләде. Марат Җәлил бистәсе мәктәбендә укытты. Хәзер алар барысы да лаеклы ялда һәм балалары-оныклары белән яшиләр.

Үз нәселебездәге мөгаллимнәр династиясе хакында язуым юкка гына түгел. Саный китсәң, әнә шундый укытучы гаиләләре бик күп безнең татарда. Шулар хакында күбрәк язасы, мәгълүматлар җыясы һәм әлеге язмаларны бер китапка туплап, дөньяга чыгарасы иде. Нигә, мөгаллимнәр династиясеннән булу горурлык түгелмени?!

## 1991 ел, 19 август

Без хатыным белән икәү Мәскәү өлкәсе Щелково районының Бахчиванджи бистәсендә яши идек. Ул Беляев урамы буйлап ике яклап тезелеп киткән биш катлы панель йортлардан гыйбарәт. Ир-ат пенсионерлар иртәләрен килә торган машинага чүп чыгарабыз, шунда очрашып яңалыклар турында сөйләшеп алабыз.

19 август көнне, чүпне машинага чыгарып салгач, мин күрше йортта яшәүче пенсионер Максимыч белән очраштым. Ул минем президентны төшерү турында ишетү-ишетмәвем белән кызыксынды. «Кичә «Вакыт» программасын каравым, әмма андый хәбәр булмады» - дидем мин. Ә Максимыч болай ди: «Безнең йорт тәрәзәсеннән бер хатын кычкырды, Горбачевны алып атканнар, диде». Моңа бер дә ышанасыбыз килмәде. Ул хатын кичә артыгын җибәргәндер дә, юньләп йоклый алмагандыр, саташып яткандыр дип гөманлады Максимыч.

Мин өйгә керергә ашыктым. Сәгать 8 дә шул хакта радиодан хәбәр ишеттем. Илдә гадәттән тыш хәл игълан ителгән, Гадәттән тыш хәл буенча дәүләт комитеты - ГКЧП оештырылган икән. Хәрби переворот турында сүз булмаса да, мин шуны аңладым: комитетка кемнәр керүенә караганда бу һичшиксез хәрби переворот, бүтән берни дә түгел. Бу хәбәрне хатыным Наилә дә тыңлаган иде, ул

Ельцинның язмышы турында бик борчылуын әйтте. Ә Ельцинның үз-үзен тотуына без һәрвакыт сокланып карый идек. СССР Югары Советына сайлау вакытында аңа булган ышанычыбызны тагын бер кат күрсәттек: күрше йортларда торучы берничә гаилә җыелып, Мәскәүгә тавыш бирергә бардык, СССР Госстрое бинасында Б.н. Ельцинны яклап тавыш бирдек.

Переворот оештыруда оборона, эчке эшләр министрларының, КГБ башлыгының катнашуы безне хафага төшерде.

Шул көнне Наилә Мәскәү-Казан поезды белән Казанга китәргә тиеш иде. Билет инде күптән алып куелган, мин Наиләгә барырга кирәк дип әйттем. Электричкага утырып Щелководан Мәскәүгә барган арада хатыным миңа өйдән чыгып йөрмәскә, бистә кибетеннән башка беркая да бармаска дип тукып барды. Әмма, Мәскәүгә җитәрәк оныгыбыз Лилиягә дигән сувенир открыткаларын онытып калдырганлыгыбыз исенә төште. Димәк, миңа иртәгә тагын Мәскәүгә килергә, окрыткалар салынган конвертны Казан поезды-ның проводницасына тапшырырга туры килә.

Икенче көнне Мәскәүгә килүгә мин кайбер урамнарда тротуар кырыйларында танклар торганын күрдем, тизрәк кире вокзалга ашыктым. Электричка вагонында пассажирларның шомланып утырганын күрдем, сүзләрен дә пышылдашып кына сөйләшәләр иде. Безнең өстә зур- зур самолетлар әйләнгәләп йөри.

Бахчиванджи платформасына төшүгә йортлар идарәбезнең өлкән электригы Петр Ивановичны очраттым. Хәрби частьның политик идарәсендә хезмәт иткән элекке офицер яшереп тормады, ГКЧПның илдә тәртип урнаштыру буенча күргән чараларын яклавын белдерде. Илебездә шундый көч куеп тергезелгән демократия тагын юк булырга мөмкин икәнлеген әйткәч, элекке офицерның җавабы катгый булды: демократларны барлык постларыннан төшерергә, һәммәсен кулга алырга кирәк. Минем аптырабрак карап торуымны күреп, өстәп тә куйды: фәкать шулай гына! «Алайса без бар-рикаданың икебез ике ягында булабыз икән», - дидем мин. Әңгәмә-дәшемнең чырае караңгыланды, ул минем яннан борылып китеп барды.

Илебездә демократлар барыбер җиңеп чыкты, Б.Н. Ельцин җинде һәм Россия Федерациясенең беренче президенты итеп сайланды.

## Яшьлегем каласы

1954 ел, Әлмәтнең шәһәр исеме алып үсә генә башлаган чагы. Уфа нефть институтын тәмамлаганнан соң мине бирегә Әлмәт-Баулы нефтүткәргече цехына эшкә җибәрделәр. Цех ике насос станциясеннән тора иде. Мине дизель белән эшли торган насос станциясенә механик итеп куйдылар, ул барак тибындагы бер иске бинага урнашкан иде.

Насос станциясе тулы көченә эшли, ягъни резерв куәте юк. Минем вазифа насос җиһазларының даими эшләвен тәэмин итүдән гыйбарәт. Озак эшләп, искергән булу сәбәпле насосларның клапаннарын еш алыштырырга туры килә иде. Бораулау измәсе кудыруга исәпләнгән насослар нефть эчендә озакка чыдамыйлар. Станцияне эштән туктатмас өчен еш кына төннәрен дә калып

эшләргә туры килә иде. Ярдәмчеләрем - үзем белән бергә карусыз, намус белән эшләгән слесарьларны әле дә рәхмәт хисе белән искә алам.

Эштән буш булган кичләрдә без өч километр ераклыктагы Тихоновка авылына җәяүләп кино карага йөри идек. Яшь киномеханикларның юньләп тәҗрибәсе юк, алар еш кына, бөтен залны көлдереп, кадрларны баштүбән күрсәтәләр иде.

Нефтьуткәргеч цехында эшләүчеләр Су-2 мәйданчыгында баракларда яшиләр, анда узебезнең клуб юк иде. Дизель-насос станциясе ябылгач, мине «Татнефтепроводстрой» (ТНПС) трестының 2нче төзү идарәсе (СУ-2) каршындагы техника күзәтчелеге инспекциясенә инженер итеп күчерделәр. Миңа төзелә торган насос станцияләре, нефтьүткәргечләр буйлап йөзләрчә километр машинада йөрергә, дистәләрчә чакрым җәяүләп атларга туры килә иде.

СУ-2 җитәкчеләре еш алышынып тора, бу башкарыла торган эшләрнең сыйфатына да суга иде. Идарәнең яңа начальнигы итеп М.З. Рыбин, баш инженер итеп Г.Е. Мандель билгеләнгәч, эшләр җайга салына башлады, эшләрнең сыйфаты да яхшырды, СУ-2 төзү мәйданчыгында да тормыш җанланып китте. Йортлар төзи башладылар, байтак эшчеләр квартир алды. Шул йортларның берсендә мин дә ике бүлмәле уңайлыклы квартир алдым. Шунда минем әти-әнием белән хатыным килде, шул квартирда ике улыбыз туды. Шунда матур, заманча клуб бинасы төзелде, Тихоновкадан кешеләр инде безнең кебек җәяүләп йөрмиләр, шәһәр транспорты йөри башлагач, автобуска утырып киләләр иде. 1962 елда миңа Татарстан Совнархозының Нефть сәнәгате идарәсендә эшләргә тәкъдим иттеләр. Идарәнең башлыгы үз эшен бик тирән белгән

тынгысыз инженер Р.Ш. Мингәрәев иде. Шундый нәрсә хәтеремдә калган: бервакыт шулай Әлмәткә бару сәбәпле Р.Ш. Мингәрәев Совнархоз хезмәткәрләренең гомуми җыелышына бераз соңга калып килгән иде, залда күренүгә коллектив аны аякка басып, көчле алкышлар белән каршы алды. Җитәкчене шулай хөрмәт итүләренә, абруе югары булуга мин сөенеп тә, аптырап та калган идем, андый хәлне беренче күрүем бит.

1964 елда Татсовнархозны бетерделәр, мин үземнең җитәкчем И.А. Бувайло белән яңа оештырылган ТатНИИнефтемаш институтына күчтем. Бу институтта мин су һәм нефть насосларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре белән дә шөгыльләндем һәм шул темага кандидатлык диссертациясе якладым. Хезмәт эшчәнлегемнең соңгы 15 елында мин Казан төзүче инженерлар институтында доцент булып эшләдем, «Насослар һәм насос станцияләре» дигән предмет алып бардым. Шул рәвешле, насослар эксплуатацияләү буенча Әлмәттә башланган эш минем гомерлек белгечлегемә әверелде.

Мин Әлмәтне хезмәт һәм гаилә тормышым башланган шәһәр итеп һәрвакыт канәгатьлек белән искә алам. Анда минем этиәниләрем җирләнгән. Казанга күчкәннән соң мин Әлмәткә еш кына эш белән барып йөри идем. Ул шәһәр белән хәзер дә элемтәләрем нык. Җәлилдә минем энем, укытучы булып эшләгән Шаммасов Марат яши. Хәзер Әлмәттә «Татнефть«тә аның улы Ленар Шаммасов эшли. Быел июль аенда улыбыз Айрат аларда кунакта булды. Без хатыным белән улыбыз Айрат янында гомер итәбез.Телевидение һәм радио хәбәрләреннән, туганнарыбыз сөйләгәннәрдән без шәһәрнең ничек үскәнен, матурланганын белеп торабыз. Яшьлегем шәһәренең шулай көннән көн яхшыра баруына, Татарстанның иң матур заманча шәһәрләреннән берсе булып әверелүенә мин ихлас күңелдән шатланам.

## Тычканлы аш

**Сезгә тәкъдим ителә торган бу язмаларның авторы Нәмикъ Шаммасов инде өлкән кеше, җитмеш тугыз яшьтә. Бүген алар хатыны Наилә апа белән Америка Кушма Штатларында уллары Айрат гаиләсендә яшиләр. Ләкин бу гаилә - без соңгы елларда гына күрешеп-аралашып йөри башлаган «чын» Америка татарлары түгел, ә берничә ел элек кенә океан арты оҗмахына күченгән кешеләр. Нәмикъ абый үзе Казанда туып, укытучы эти-әнисе белән Мари республикасында, сонрак Ютазы**

**районында яшәп үскән кеше. Укып, фәннәр кандидаты булгач, Нәмикъ абый Казанда, төзелеш институтында (хәзер архитектура-төзелещ академиясе) укыткан. Улы Айрат та, этисе юлыннан китеп, Санкт-Петербургта техник белгечлек алган. Галим егетнең Америкага да кирәге чыккан.**

Совет Армиясендә солдат тормышы билгеле бер режимга салынган. Ләкин минем алты еллык солдат хезмәтендә төрле үзенчәлекле вакыйгалар да булды. Шул вакыйгалар арасыннан татарлар катнашкан берничә хәлне тасвирлап китәм.

1948 елда мин штаб бүлмәсендә, хәрби частьнең байрагы янында сакта торганда, күрше бүлмәдә подполковникның кемнедер сүккәнен ишеттем: «Ты, татарин, басурманин, как посмел уговорить солдат не принимать готовую пищу в столовой? Запомни, никакого мышонка в супе не было…»

Бу кимсетү сүзләрен ишеткәч, мин каты итеп йөткердем һәм мылтыкның прикладын белән идәнгә шакыдым. Шул тавышны ишетеп булса кирәк, подполковник байраклы бүлмәнең ишеген ачып кермәкче булды. Мин: «Стой, кто идет? Стой, стрелять буду!» - дип кычкырдым һәм мылтыгымның затворын тавышландырып ачып, бер патронны атарга әзерләдем. Подполковник, кире борылып, үз бүлмәсенә китте һәм телефоннан каравыл башлыгына чылтырата башлады. Озакламый каравыл башлыгы, мине посттан алып, урыныма икенче солдатны куеп калдырды. Подполковникның кабинеты янынан узганда, мин аның бүлмәсендә басып торучы, безнең ротада хезмәт итүче фронтовик-сержантны - татар егетен күреп киттем. Подполковник шул сержантны шелтәләгән икән. Каравыл башлыгы мине башка постка куйды. Каравылдан кайткач, татар егете миңа замполитның үзен нигә әрләгенен аңлатты.

Төшке аш вакытында болар өстәлендәге кәстрүлдән тычкан үләксәсе чыккан. Ротаның барлык солдатлары да, бу хәлне күреп, ашны ашамас булганнар. Замполит исә, дөнья бутаучы дип сайлап алып, сержант татарны үзенең кабинетына чакырып сүгәргә тотынган. Гауптвахтага утыртам дип куркыткан, ләкин, күршедә минем тавышланганны ишеткәч, сержантка: «Вон из моего кабинета!» - дип кычкырган. Бувакыйга шуның белән тәмамланса да, минем өчен аның көтелмәгән дәвамы булды. Подполковник, сержантны кимсетеп сүккәндә шаһит булуымны онытмыйча, мине

каты җәзага дучар итмәкче булды.

Солдат тормышы тыныч елларда һәр көнне иртәнге физзарядка белән башлана. Ләкин, физзарядкага чыккач, һәр взвод бәдрәфкә йөгерә. Бер көнне мин үзебез төзегән 20 урынлы бәдрәфкә кергәч: «Кемдә дә булса берәр үзәк газета юкмы? Ул йомшаграк була, безнең «Боевой листок» катыргыдай каты кәгазьле»,
-дип кычкырдым. Бәдрәфтәге солдатлар көлештеләр. Аннан соң, физзарядканы ясагач, юынып, чистарынып, ашханәгә иртәнге ашка киттек. Аннан кайтып, кирәкле әсбапларны алып, иртәнге дәрескә барырга җыенганда, дежурдагы офицер ике солдат белән килеп, мине тоткын итеп гауптвахтага алып китте.

Безнең частьнең гауптвахтасы землянкада урнашкан, аның тәрәзәсе юк, ә ишеге каравыл бүлмәсенә чыга. Йоклар өчен тактадан ясалган ике катлы киштәләре бар. Каравыл начальнигы мине сак астына алуының сәбәбен иртән бәдрәфтә аполитик сүзләр сөйләвем өчен дип аңлатты. Замполит кушуы буенча син тикшерү астында, беркем белән дә сөйләшергә хакың юк дип өстәде. Өч көнгә бер безнең радиорота дежурда булганда егетләр аша мин ротадагы яңалыкларны белеп тордым.

Бәдрәфтәге сөйләшүне замполитка яңа килгән взвод командиры тапшырган икән. Соңыннан безнең рота сержантлары аңа «темная ясыйбыз» дип куркытканнар һәм аны башка частька күчергәннәр. «Темная» - ул арттан килеп башны юрган белән томалау һәм җыелышып кыйнау. Мин 26 көн гауптвахтада уздырдым. Армия күләмендәге штаб өйрәнүләрендә катнашыр өчен мине гауптвахтадан чыгардылар һәм үзебезнең радиостанция белән ротаны Белорусиягә җибәрделәр. Мин 1 нче класслы радиотелеграфист идем. Хәрби радистларга минем «кул» билгеле булганга, учениедә минем катнашу кирәк дип табылган. 15 көнлек өйрәнүләрдән кайткач, мине частьнең парторгы майор Галимов үз кабинетына чакыртты һәм безнең частьта уздырылган партҗыелыш беркетмәләрен күчереп язарга кушты. Партия әгъзасы булмасам да, ул миңа мөрәҗәгать иткәли иде. Элек язылган беркетмәләрнең караламалары күбесе аңлаешсыз һәм бик надан язылган була иде. Майорның күзәтүе астында кичкә хәтле язып утырдым. Язулардан тукталып торганда майор минем әти-әниләр турында да сораштырды. Мин аның сорауларына һәм безнең гаиләне белүенә гаҗәпләндем. «Миңа, синең әти-әниең яшәгән җирләргә барып, алар турында мәгълүмат алып кайтырга туры килде. Аларның күп еллар буе укытучылар булып эшләүләре, абруйлары сине тоткынлыктан

коткарырга мөмкинлек бирде. Билгеле, замполитны килештерүе җиңел булмады», - диде ул. Мине коткарырга булышканы өчен аңа рәхмәт әйттем. «Милләтемнең гаепсез кешеләрен яклап кала алганда мин бик канәгать булам», - дип сүзне тәмамлады майор.

Майор-парторг, мине тагын берничә мәртәбә чакырып, беркетмәләр яздырды. Бер елдан соң майорны икенче частька күчерделәр, һәм мин аңың белән бүтән очрашмадым Татар егетләренең хәрби хезмәттә дә бер-берсенә мөмкин кадәр ярдәм кулы сузуы минем күңелгә тирән кереп калды.

**Нәмикъ Шаммасов,**
**техник фәннәр кандидаты.**

## Горур кәҗә

Тышкы ишекнең әкрен генә ачылу тавышына язу өстәле янында утырган урынымнан башымны борып карадым. Өстенә камзул рәвешендәге плаш кигән, башына җинел шәл бәйләгән, иңбашына җитәрлек таякка таянган сөлекче әби ишектән кереп килә иде. Битләре шактый җыерчыклы булып, шәл астыннан чал чәчләре дә күренеп торуга карамастан, әбинең күзләре бик тере карыйлар һәм аның йомыкый кеше түгел икәнлеген күрсәтәләр иде.

Сөлекче әби безнең кебек үк Әлмәттә яши. Ул, атнасына бер-ике
мәртәбә безгә кереп, авыру этинең хәл-әхвәлен белешә. Аның белән сөйләшкәннән соң этинең дә күңеле күтәрелеп китә. Шуңа күрә исәнлек-саулыкны сорашкач һәм этинең әле генә йоклап китүен әйткәч, мин әбине бераз хәл алдыру нияте белән чәй эчәргә чакырдым.

Әби, өстендәге плащын һәм аягындагы галошларын салып, кул юарга кереп китте. Ә мин, аш өстәленә күмәч, май, шикәр куеп, чынаякларга чәй ясый башладым.

- Аш-су әзерләвең өчен сиңа зур рәхмәт, энем, - диде әби өстәл янына килеп. Һәм, бисмилла әйтеп, чынаяк тәлинкәсен үзенә якынрак тартты. - Мин, арырлык еmenактан килмәсәм дә, чәй эчүне мәслихәт табам.
Мин әбинең тормышы белән кызыксынып;

- Әби, син безгә ДСРК тукталышыннан килеп йөрисең. Анда кемнәр белән торасың? - дип сорадым.

- Мин улым гаиләсе белән үзебез салган йортта яшим. Авылдан күчеп килгәндә сыерыбыз, сарыкларыбыз да бар иде. Хәзер барлык мал-туарыбыз бер кәҗә һәм биш-алты тавыктан тора, - дип җавап

бирде әби.

Икенче чынаяк чәйне ясаган арада ул сөйләвен дәвам итте:

- Синең әтиең, Хәлил абый, пенсиягә чыкканчы күп еллар укытучы булып эшләгән. Егет чагында ул мәдрәсәләрдә гарәп телен һәм ислам дине нигезләрен өйрәнгән. Коръән сүрәләренең мәгънәсен миңа ул аңлатып бирә. Менә ул, кәҗә турында сүз чыккач, бер гарәпчә-татарча әйтем китергән иде: «Мәл фәрекъ бәйнел кәҗә вә сарык». Татарча итеп әйткәндә: «Кәҗә белән сарыкның аермасы нидә?» Гарәпчә әйтем матур булса да, минем кәҗәнең сарыктан аермасы бик зур, чөнки аның үзенә күрә хосусыйлыгы бар. Шулай бер көнне килен улымны соңгарак калып кайтуы өчен ишегалдында кычкырып шелтәли башлады. Бу тавышны кәҗә дә ишетеп торды. Инде үзара сөйләшеп тынычлангач, килен кәҗәне саварга киткән җиреннән: «Әни, үзең монда кил, кәҗәң үпкәләде - сөт бирми», - дип мине чакырды. Мин тиз генә кулларымны юып кәҗә янына килдем дә әкрен генә кәҗәнең җилемен, муенын сыйпап: «Алар сине ачуланмаганнар, үпкәләргә кирәкми», - дип үгетләп кәҗәне саудым.

Мин кызыксынып:

- Кәҗәнең сөт бирүдән туктап торуы, бәлки, тавыштан куркып сискәнеп китүдән генә буладыр, - дидем.

- Ачуланып кычкыруга ул һәрвакыт сөтен тоткарлата. Хәзер ул хәлгә гаҗәпләнмибез дә инде. Күптән түгел кәҗә белән тагын сәер хәл булды бит әле. Бер көнне яңа сөлекләр алырга Казанга киттем. Мин шулай Карл Маркс урамындагы аптекадан сөлекләр алып кайткалыйм. Гадәттә мин көне белән әйләнеп тә кайтам. Ләкин әлеге баруда туган-тумачаларга кереп, кунып калырга туры килде. Әлмәткә икенче көнне генә әйләнеп кайттым. Өйдә хәвефле хәл булганы киленнең йөзеннән күренеп тора иде.

- Килен, өйдә исән-саулыктыр бит, нигә син болай күңелсез? - дип сорадым.

- Балалар да, үзебез дә, аллага шөкер, исән-саулар, әни. Тик син киткәч шомлы хәл булды бит әле. Ул да булса - кәҗә юкка чыкты. Кичә эштән кайткач, тирә-яктан эзләп тә караган идек, ләкин тапмадык. Мин инде, уйлый торгач, кәҗә миңа үпкәләгән булса кирәк, дигән фикергә килдем. Чөнки син Казанга киткән көнне мин кер юып, ишегалдында бауга элгәндә кәҗәне төрткәләп капкадан куып чыгарган идем. Гадәттә ул үзебезнең урамнан китми торган иде бит, - дип килен хәлне аңлатты.

Шул вакыт капка ачылып, күрше хатынның: «Әби, сезнең кәҗәне электр подстанциясе янында, нефтьчеләрнең иске будкасы тирәсендә күргәннәр, алып кайтыгыз», - дигән сүзләре ишетелде. Шушы хәбәрне ишеткәч, мин, оныгымны ияртеп, кәҗә янына

ашыктым. Без барып җиткәндә ул чирәмдә күшәп ята иде. Мине күргәч, авызын ачмыйча гына күкрәк тавышы белән мәэлдәп куйды. Шулай итеп шатлыгын белдерде булса кирәк. Үзем белән алып барган ипи кисәген сындырып бирдем дә муенын, мөгез төпләрен сыйпый-сыйпый: «Без сине югалтып йөрибез, әйдә, кайтабыз», - дип үгетләп өйгә алып кайттым. Ишегалдында килен кәҗәне саварга әзерләнгән иде инде. Ул да: «Кәҗәкәем, син миңа үпкәләмә инде», - дип, әкрен генә саварга тотынды. Менә шулай минем кәҗәнең горурлыгы бар һәм һәр җан иясе кебек үз ихтыярын үзе сакларга тырыша», - дип фикерен йомгаклады әби.

**Н. ШАММАСОВ,**
**сугыш һәм хезмәт ветераны.**

**Annotatsiyä**

Bu kitaptağı yazmalarnıñ awtorı nigezdä ber keşe - bu köndä Ameriqa Quşma Ştatlarında ulı ğäiläsendä gomer itüçe Nämiq Şammasov. Ämma kitapta anıñ xatını Nailä belän bergä yazğannarı da, enese Marat Şammasov yazğan istälek tä, Şam-masowlar ğäiläse turında jurnalist F. Möxämmätowa oçerqı da urın alğan. Törle yıllarda, törle ğäzetalarda basılıp çıqqan yazmalar ğömerlären uqıtuçılıq eşenä bağışlağan öç tuğan - Nayad, Nämiq häm Marat turında, alarnıñ äti-äniläre, ğömerlären xalıq mäğärifenä bağışlağan Xälil häm Mösaffa Şammasowlar turında bulsa da, alarnıñ yazmışları aşa bez küp närsälär belän tanışabız. Küñelle dä, ğibrätle dä balaçaq yılları, suğışqa qädärge şomlı repressiyä çorı - ber ğayıpsez keşelärne qulğa alu, yuq itülär dä, suğış çorı awırlıqları da, okean artında tormış itü üzençälekläre dä - hämmäse-hämmäse keşe yazmışları arqılı canlı bulıp küz aldına basa, ber ğäilä tormışında il yazmışı çağılış taba. Yazmalar tematik häm xronologik yaqtan mömkin qädär ezlek-lelek belän täqdim itelä.

## Qaban küle malayları

Bez, öç bertuğan malay, iske Qazanda Qayum Nasıyri uramın - dağı 10 nçı yortta tuwıp üstek. Balaçaq häm kürşelär ber dä istän çıqmıy.

Kürşelär digändä, älbättä, berençe çiratta Täzkirä apadan başlarğa kiräk. Täzkirä apa bu yortta yäş çaqtan uq Borhan mullada asraw qız bulıp xezmät itä başlağan. Ul yaşi torğan keçkenä genä bülmä elek xucalar öçen çäy äzerläw urını bulğan. Mäşhür tatar yazuçısı Ğälimcan İbrahimownıñ da, Borhan mullağa kilgändä, şuşı bülmägä kerep çäy eçä torğan ğädäte bulğan.

Bez belgändä Täzkirä apa bolnitsada sanitarqa bulıp eşli ide. Bezneñ uramda ğına tügel, ä Qazannıñ bütän iske uramnarında da anı belälär ide. Ul bik açıq küñelle xatın bulıp, kilgän ber keşene çäy eçermiçä çığarmıy ide. Şunıñ öçen dä suğış başlanu belän Täzkirä apa öçen iñ zur küñelsezlek - aş-su äzerläp, Qor'än uqıta almaw buldı. Täzkirä apanıñ bezdän berniçä yäşkä olıraq Söyembikä isemle qızı barlıq öy eşlären başqarıp tora. ide. Bala çaqtan uq ul bezneñ işe kürşe malayların üz tuğannarı kebek kürde: bezne kiyenderep baqçağa ozatu häm qarşı alu härwaqıt anıñ östendä ide. Gomumän, Söyembikägä dä, änise kebek ük, samimilek, saf küñellelek xas buldı.

Kiñ küñelle Täzkirä apa tuğız qwadrat metrlı bülmäsendä ayırılğan ireneñ ätisen, änisen häm köndäşeneñ minem yäştäge Qämil isemle malayın da sıydırıp yäşäde. Şul uq bülmädä Täzkirä apanıñ awıldaşı Qämäriyä apa da un yıldan artıq tordı. Qämäriyä apa başta sanitarqa bulıp eşläde, ä suğış aldınnan, yöräk çire arqasında, eşli almadı. Suğış başlanu belän anıñ keçkenä genä pensiyäsen dä birmäs buldılar. Ul kön sayın kerosin çiratına yöri ide. Çirat «satıp», litrına 1 tiyen kerem alıp tora başlağan ide, läkin ozaq ta ütmäde, salqın tiderep qayttı da, berniçä könnän ülep tä kitte. Kürşelär anı cıyılışıp kümdelär, çönki anıñ ber tuğanı da, ber sum aqçası da yuq ide.

Suğış başlanu belän, cidençe sıynıftağı Qämil, uquwın taşlap, satu eşenä kerde häm üz änise ğäiläsenä - Yaña bistägä qaytıp kitte. Şulay itep, Täzkirä apa bülmäsendä altı keşedän dürtäw qaldılar.

Gomumkoridorda Täzkirä apa bülmäsenä kerüçe işek yañağına terälep toruçı su miçkäse häm yuwınğıç - ikençe kürşelärneke. Alarnıñ fatir işege koridornıñ türendä. İrle-xatınlı Färrax abıy belän Naciya apa, qızları Lyalya (Lälä tügel, näq menä Lyalya), malayları Rafael belän şul fatirda toralar. Färrax abıy, ğömere buyı kibettä eşläp, ğäiläsen yaxşı tä'min itep tordı.
Suğış başlanıp, gomumi mobilizatsiyä iğlan itelü belän, Färrax

abıy kostyum urınına gimnasterqa kide, leytenant qübiqları tağıp yöri başladı. Xatını Naciya apa belän alar gel äytkäläşep, ızğışıp tordılar. Bälki şul säbäptänder, Färrax abıy öydä siräk kürenä ide (ällä kiresençä, öyenä siräk qaytu säbäple süz çığa torğan bulğandır). Anıñ qaravı, Naciya apa ber waqıtta da eşlämäde häm, köne buyı öyendä bulıp, kürşelärgä tınğılıq birmäde. Ul, Nadejda isemle marca bulıp, tatar awılında tärbiyälängän. Kiyäwgä çıqqanda, möselman dinen qabul itep, Naciya isemenä yazılğan. Urısçası şäp. Şul uq waqıtta işeğaldındağı ikençe binada yäşäwçe urıs tele uqıtuçısı urıs telen ostarak belä, läkin ul Naciya apa belän söyläşü genä tügel, oçraşmasqa da tırışa ide.
Ul uqıtuçınıñ ire elek yuğarı urında eşläde. Eşkä dä avtomobil belän genä alıp kitälär ide. 1937 yılda anı «xalıq doşmanı» dip ğayıpläp qulğa aldılar häm ozaq ta totmıyça attılar. Şunnan soñ anıñ ike bala (bezneñ yäştäşlär) belän qalğan xatının uqıtuçılıq eşennän qudılar, ğäiläsen, dürt bülmäle fatirdan çığarıp, ber genä keçkenä bülmädä qaldırdılar. Minem äni, uqıtuçı bularaq, ul xatın belän uramda ğına oçraşıp söyläşä ide. Naciya apa kürüwennän qurqıp, alar ber dä bezneñ fatirda oçraşmadılar, çönki Naciya apanıñ «orğannarğa» barlıq kürşelär turında xäbär citkerep toruwı bilgele bulğan.
Naciya apa, köne buyı öydä torıp, gomumkoridorğa kerüçelärne üzeneñ däftärenä yazıp bara ide. Şul xisaplar nigezendä ul gomumkoridor idänen yumıy, koridordağı lampoçqağa aqça tülämi ide. Berwaqıt şulay, 1940 yılda, ätineñ tuğan awılı Çulpannan kilgän ike keşene qunaq itü 21 ğıynwarğa turı kilde. Qunaq östäle artında utıruçılar äkren genä cırlıy başlağaç, Naciya apa işekne qağıp: «Yulbaşçıbız Lenin ülgän köndä niçek küñel açıp utırırğa mömkin? Xäzer ük tiyeşle urınğa xäbär itäm!» - dip qıçqırdı. Bilgele, şundıy qurqınıç kisätüdän soñ mäcles xalqı tiz-tiz cıyınıp, qaysı kaya taralıştı. Elek tä, 1937 yılda qulğa alınıp, ber yıl utırıp çıqqannan soñ äti politika turında söyläşmi torğan buldı.
Ber genä yawız kürşe barlıq matur dönyanı, küñelle duslarnı ciñä almıy ide, älbättä. Bala çaqtan uq yış aralaşqan qäyber kürşelärne dä äytep uzası kilä.
Bez, balalar, awırıy başlasaq, ber tabib kilep qarıy ide. Ul tabib urıs bulsa da, tatarça yaxşı añlaşa häm anı xalıq telendä «Kügärçen» dip atıylar ide.
İrlär çäçen aluçı erman quşamatlı ber pariqmaxer da bezdä bulğalıy ide. Ul bik açıq küñelle, küpne kürgän, berençe german

suğışında qatnaşıp, äsirdä bulıp qaytqan keşe ide. Parikma-
xerlıq hönären ul äsirlektä üzläştergän häm üz eşen bik yaratıp

başqara ide. Suğış başlanu belän anı qulğa alıp, şpionlıqta ğayıpläp, törmädä atuların bezgä soñınnan anıñ yäş xatını Räbbiğa apa söyläde. Tuqay uramında toruçı Şakir abıy xatını Särwäri apa belän bezgä yış qına kilälär ide. Şakir abıylarnıñ üz balaları bulmadı, şuña kürä bezne üzlärenä çaqırıp, üze yasağan radioalğıçnı kürsätä ide. Radioalğıç ber metr çaması biyeklektäge häm kiñlektäge ber ağaç tartma eçendä tora, zur lampoçqalardan cıyılğan. Minem ätigä şul radioalğıç aşa Törkiyädän tapşırılğan ğäräp telendäge Qor'än uqular bik oşıy ide. Suğış başlanu xäbären dä Şakir abıy Törkiyä radiosınnan 22 iyündä irtän ük işetep, bezgä xäbär itkän ide. Läkin suğış başlanu belän Şakir abıynı, radioalğıçı belän bergä törmägä alıp kittelär, ä ozaq ta ütmäde, Särwäri apa anıñ törmädä atılu xäbären kilep söyläde.

Şul waqıtta aralaşqan barlıq kürşelärne sanap beterü mömkin tügel. Şulay da bezneñ küñeldä saqlanğan Şäwkät turında äytmiçä bulmıy. Ul uzyeneñ namuslılığı belän ayırılıp tordı.

Bezneñ olı abıyıbız Nayad häm Şäwkät ikese dä osta oeştıruçılar ide. Alar, keçeräk balalarnı «Çatqı» kinoteatrına alıp barıp, yaña filmnar qarawnı oeştıralar ide. Şular arasında «Çapayıw»-nı 13 märtäbä qaraw, «Wratar», «Traqtoristı», «Veselıe rebyata» häm başqa şundıy filmnarnı qaraw istä qalğan. Ä cäyge qanikul çorlarında Şäwkät belän Nayad futbol yarışları oeştıralar ide.

Tik şunısı qızğanıç, suğıştan soñğı yıllarda Şäwkät, xämer belän mawığıp kitep, waqıtsız wafat buldı.

Bezneñ işeğaldında ikençe binanıñ arğı başında 45-50 yäştäge Xäsän abıy yäşäde. Suğışqa qädärge çorda bu abzıy bezneñ öçen armas-talmas xezmät keşese bulıp istä qaldı. İşeg-aldındağı keçkenä genä alaçığında ul närsäder yasıy, tözätä ide.

Soñınnan bez anıñ osta qullı qalayçı, qurğaş belän yabıştıruçı, buş konservı sawıtlarınnan törle sosqılar, krujqalar, büränkälär yasawçı ikänlegen beldek. Anıñ här yasağan äybere maturlığı häm yuğarı sıyfatı belen ayırılıp tora ide.

Nasıyri uramındağı 10 nçı yort - ul bezneñ tuğan yortıbız.

Bez torğan yort - tarixqa kerep qalğan olı din ähele, filosof, mäğrifätçe Şihabetdin Märcani yortı da äle ul. Ul wafat bulğaç, revolyutsiyägä qädär monda Borhan mulla yäşägän.

Gomer uza, zamanalar üzgärä. Bezneñ belän kürşe bulıp yäşägän ğäilälärneñ barısı da diyärlek bu yortta yuq inde. 2001 yılnıñ iyülendä bez, abıy belän Qazanğa barğaç, kürşebez Lyalyanı häm

Şäwkätneñ xatının kürdek. Alar da xäzerge köndä başqa urınğa - Qazandağı yaña yortlarnıñ bersenä küçerelgän bulırğa tiyeşlär.

**Nämiq ŞAMMASOV,**
**suğış häm xezmät veteranı, texnik fännör qändidatı.**
**Marat ŞAMMASOV,**
**xezmät veteranı, RSFSRnıñ mäğärif otliçniğı.**
**Sarman rayonı, Cälil bistäse.**

Şammasowlarnıñ ğäilä arxiwınnan alınğan räsemnärdä: kürşelär belän 1940 yılda bergä töşkän fotoda awtorlarnıñ ätise häm änise (artta, uñnan berençe häm ikençe, yazmada telgä alınğan Täzkirä apa - alğı rättä, suldan berençe). Abıylı-enele Nämiq häm Marat Şammasowlar üzläre tuwıp-üskän yort yanında. Märcanidan soñ da küplärne üzenä sıyındırğan tarixi yort.

## Qaban külendä «säklär»

Älege yazmanıñ awtorı Nämiq Şammasov ozaq yıllar tözeleş injenerları institutında uqıta, texnik fännär qändidatı. Xäzerge waqıtta ul xatını Nailä xanım belän eraq Ameriqada ulları Ayrat tärbiyäsendä yaşi. Anıñ istälek däftärennän bu özekne bezgä Sarman rayonınıñ Cälil bistäsendä gomer itüçe enese Marat Şammasov täkdim itte. Yazma 1000 yıllıq Qazanıbız tarixınıñ bezgä mäğlüm bulmağan yaqların çağıldıra.

Çıñğıldap pıyala watılğan tawış işetelde häm täräzä aldına yodrıq xätle taş kilep töşte. Şulwaqıt işektä kürşe qlassta uquçı Şäwkät kürende. Ul miña qarap: «Nämiq, säklär kilgän, qlassığızdağı malaylarnı cıy! Nayad anda uquçılarnı kütärä, ä min Mäxmütlärne çaqırıp kiläm», - dide. Nayad 4 nçe qlassta uqıy, ul minem bertuğan abıem häm mäktäp malaylarınıñ yulbaşçısı. Ä «säklär» dip Sukonnıy bistäsendä yäşäwçelärne atıylar ide.

Bez uramğa çıqqanda Nayad yanına başqa qlass malayları cıyılğan ide inde. 1936 yıl ide bu. Min ul çaqta elekke Kül buyı mädräsäse binasında urnaşqan tatar mäktäbeneñ 3 nçe qlassında uqıym. Ul fasad yağı belän Qaban külenä qarap tora. Bez şul binadan çığıp kül yarında tezelep bastıq. Boz östendä cıyılıp torğan säklärne küzättek. Küp tä uzmadı, Nasıyri tıqrığınnan bezneñ yaqnıñ 4-5 yegete yärdämgä kilep citte. Bez alar artınnan:

«Qaban naşe, ne waşe, säklärgä taw başı», - dip qıçqıra-qıçqıra
alarnı quwıp kittek. Külneñ urtasına citkäç, kire borıldıq. Ä

uquçıları arasında ğına tügel, ä uqıtuçılar tarafınnan da
ixtiram qazandı. Şulay berwaqıt, Nayadnıñ rus telennän awır
uquwın belgäç, uqıtuçı Märğübä Qolaxmätowa anı üz öyenä çaqırıp
östämä däreslär uzdıra başladı. Şul yärdämne onıtmıyça, Nayad
tä küp yıllar däwamında Märğübä apanı olıladı. Xätta ul Ufa
neft institutında qäfedra mödire bulıp eşlägändä dä Qazanğa
kilgän sayın Märğübä apa yanına kerep xälen belä ide.
Menä şulay tatar yegetläre, ike çor däwamında üz millätenеñ
gorurlığın saqlap, Qaban külendäge köräşlärdä aktiv qatnaşıp,
olığayğaç ta däräcäle keşelär bulıp xezmät itälär.

## Bärãñge awılında sörgendä

1932 yılnıñ avgust ayında bezneñ qwartirğa militsiyä keşeläre
kilep tentülär yasadılar, barlıq kitaplarnı,yazu-sızularnı,
östäldä eskäter astında yatqan xatlarğa qädär tikşerdelär. İke kön
rättän aqtarınğannan soñ ätine üzläre belän alıp kittelär.
Berniçä könnän äniyebez ätineñ Plätän törmäsendä utıruwın
beleşep qayttı. Şunnan soñ äni ya Nayadne, ya mine iyärtep ätigä
peredaçalar iltep yörde. Bezgä äti belän küreşergä röxsät
itmädelär.

1933 yılnıñ iyün ayında äti öygä qayttı. Törmädäge xällärne ul
bolay söyläde. Tikşerüçe soraw alğanda törle dokumentlarğa
quyılğan yalğan (poddelnıy) imzalarnı ätineñ qulı dip tanıtırğa
tırışqan. Mulla malayı bulğan öçen soñğa taba ätine millätçelektä
ğayıplärgä mataşqan. Tikşerüçe soraw alırğa tönlä çaqırta,
pistoletın östälgä quyıp «eşkä» totına ikän. Azat itär aldınnan
tikşerüçe ätigä ğäiläse belän Qazannan ike yılğa sörelüwen äytkän,
yağni bez mäcbüri räweştä Qazannan 2 yılğa kitep torırğa tiyeş
ikänbez. Şulay itep, 1933 yılnıñ avgust ayında bez ğäiläbez belän
Mari respublikasındagı Bärãñge awılına kilep urnaştıq.
Bärãñge rayon üzäge, tatar awılı, anda yaña peduçilişçe
açılğan ide. Äti belän äni ikese dä şunda uqıtuçı bulıp eşli
başladılar. Äti fiziqa uqıttı, äni tatar telennän däreslär
birde.

Awılğa kilü belän äti rayon eçke eşlär bülege citäkçese Xustin yanına kerep, üzeneñ Qazandağı xällären söyläp, monda mäcbüri cibärelüwen xäbär itep çıqtı. Anıñ yanınnan qaytqaç, äti bik şatlanıp bolay dip söyläde: «İptäş Xustin bik mäğlümatlı keşe bulıp kürenä. İtağätlelege belän dä Plätän törmäsendäge tikşerüçelärdän yuğarıraq tora».

1934 yılnıñ sentyabrendä Nayad mäktäptä Znçe qlassta uqıy başladı. Uqıy-yaza belüwemne iskä alıp, mine dä 2nçe qlasska aldılar. Üz qlassındağı uquçılar belän bergä Nayad qışın çañğıda rayon awılları buylap agitqöllektiwta yörde. Alar S.M. Kirownıñ üterelüwen xalıqqa xäbär itep yördelär.
İke yıldan soñ, uqu yılı betügä bez aşığıç räweştä Qazanğa qaytıp kitärgä cıyına başladıq. Ä bez, malaylar, cäyne awılda balıq totıp, ciläk cıyıp, yal itep uzdırırğa uylağan idek. Änidän bolay aşığunıñ säbäben sorağaç, cawabı qısqa buldı: «İptäş Xustin ätiyegezgä şulay quşqan». İptäş Xustinnıñ aşıqtıru säbäben bez soñraq, berniçä yıl ütkäç kenä añladıq.
1935 yılnıñ awğustında bez Qazandağı elekke qwartirıbızğa qaytıq. Bez yuğında anda yäşägän Salix abıy ğäiläse Bolaq buyındağı bütän qwartirğa küçep kitte. Äni Qazan pedagogiyä institutında uquwın däwam itte. Äti Kirov rayonındağı urta mäktäptä fiziqa uqıtuçısı buldı. 1935-36 uqu yılında elekke Kül buyı mädräsäse binasında urnaşqan tatar mäktäbendä Nayad 4nçe qlassta, min Znçe qlassta uqıy başladıq.
Bäräñgedän bötenläygä küçep kitsäk tä, andağı küp tanış-beleşlär Qazanğa kilgändä bezgä kerep çäy eçep çığalar, andağı faciğäle xällärne söylilär ide. Ul waqıtta Bäräñgedä ütkärelgän repressiyägä eläkkän awıl citäkçeläre, uqıtuçılar turında ğäzetalarda mäqälälär basılıp çıqtı. Şular arasında bez belgän keşelär: peduçilişçe direqtorı Tahir Mäxmütov, peduçilişçedan zavuç Qayum Bigäşev, urta mäktäp direqtorı Näcmetdinov, urta mäktäp uqıtuçısı Ğabdulla İjbulatov ta bar ide. Alar barısı da qulğa alınıp atıp üterelgännär. Bäräñge awılın oeştıruçılarnıñ berse uqımışlı mulla Bayazetdin Ğayazowqa şulay uq «millätçe» dip ğayıp taqqannar, atıp ütergännär. Soñınnan bu keşelär reabilitatsiyälände. Ul waqıtta millätebezneñ tarixın, goref-ğädätlären öyränergä, saqlap qalırğa omtıluçı fän häm din ähellärenä şulay repressiyägä elägü qurqınıçı yanap tora ide.
Bäräñge rayonınıñ MVD bülege citäkçese Zinnät Xustinnıñ yuğarıdan kilgän repressiyä boyırıqların ütärgä vöjdanı quşmağan. Ä boyırıqnı ütämägän öçen üzenä ülem cäzası yanawın ul

yaxşı belgän, näticädä qäbinetında üzen üze atıp ütergän.

1936-1938 yıllardağı repressiyälär qabatlanmasın öçen ğayıpsez ezärleklängän, üterelgän şäxeslärne onıtmasqa, istä totarğa kiräk. Ul yıllarda repressiyä tegermänenä eläkkän millionnarça ğayıpsez keşelär üzebezneñ äti-änilär, äbi-babaylar bit.

## Erman-pariqmaxer

Ütkän ğasırnıñ 30nçı yıllarında bezneñ ğäilä Qazan şähären-dä K. Nasıyri uramındağı 1Onçı yortnıñ 4nçe qwartirında yäşäde. Şul yıllarda bezgä daimi räweştä ber çäç tözätü ostası kilep yörde. Berençe bötendönya suğışında qatnaşıp, ermaniyädä äsirlektä bulıp qaytqan öçen anı «erman» dip yörtälär, bu quşamat aña tämam yabışqan ide.

Erman bezgä bilgelängän waqıtqa kilep citä, ätine idän urtasındağı urındıqqa utırta, keçkenä çemodanın aça, çäç tözätü qoralların cäyep sala da eşkä kereşä. Ağalı-enele öç malay - bez, çittäräk utırıp, pariqmaxernıñ eşlägänen küzätäbez, anıñ üze turında söylägännären qızıqsınıp tıñlıybız.

Ul frontta yaralanıp äsirlekkä eläkkän ikän. Nemets gospitalendä ozaq qına däwalanğaç, anı ber nemets ğäiläsenä eşkä birälär. Xuca nemets äsir tatarnıñ tırışlığın, pöxtälegen bik tiz kürep ala, anı üzenä yärdämgä pariqmaxer hönärenä öyrätä. Ozaqlamıyça tatar keşese osta çäçtaraş bulıp citeşä.

Suğış betep, äsirlärne tuğan illärenä qaytarır waqıt citkäç, nemets tatar-äsirgä ermaniyädä qalırğa, üze belän bergä eşlärgä täqdim itkän. Läkin äsir rizalaşmıy, xucağa räxmät äytep, tuğan cirenä, Qazanğa qaytası kilüwen belderä. Sawbullaşqan çaqta nemets äsirgä keçkenä genä çemodan belän ermaniyädä eşlängän çäç alu qoralları cıyılması büläk itä. Üz ilenä qaytuğa elekke äsir Qazan şähäreneñ Yaña bistäsendä üzeneñ çäçtaraşxanäsen açıp cibärä, ä «erman» süze anıñ quşamatı bulıp qala.

Ätineñ çäçen alğan arada erman çit ildäge tormışnıñ ğibrät alırlıq küreneşlären söyli ide. Mäsälän, ermaniyädä eşkä kilgän törek ğäilälärenä mäçetlär salırğa, islam dine taläplären ütärgä, şäriğät quşqança yäşärgä, härkemgä küñelenä xuş kilgän käsep belän şöğellänep, matur tormış qorırğa mömkinlek birälär ikän.

Mondıy süzlärne işetkäç, äti, çäçtaraşnı süzennän tuqtatıp çit ildäge tormış turında fikerlären qıçqırıp söylämäskä

kiñäş birä, mondıy süzlärne xökümät keşeläre, orğannar propağanda dip isäplärgä mömkin diyä ide. 1938 yıldan erman-pariqmaxer bezgä kilmi başladı, bez anıñ turında xäbärsez qaldıq.

Anıñ xäbäre bezgä küp gomer ütkäç kilep ireşte. 1978 yılda bez ğäiläbez belän G. İbrahimov prospektındagı qwartirğa küçtek. Yaña kürşelärebez Käşşaf abıy belän Räbiğa apa ikese dä bik açıq tabiğätle keşelär, olı yäştäge pensionerlar bulıp çıqtılar. Käşşaf abıy Watan suğışında yaralanıp qaytqan, inwalid, könnären kübesençä qarawatında yatıp, radio tıñlap uzdıra. Räbiğa apa isä könnär buyı kergän keşelär belän söyläşep, buş waqıtlarında kitap uqıp ta utıra. Qwartirlarınıñ işege köndez härwaqıt biklänmägän bula, kürşelär ğädättä alarğa açqıçların qaldırıp kitälär.

Berençe tanışuda uq Räbiğa apa üzeneñ tormış yulın söyläp birde. Ul keçe yäştän ük yätim qalğan, 14 yäşennän tatar ğäiläsendä bala qarap xezmät itkän. Kürşelär kiñäşe belän Räbiğa 16 yäşennän tatar pariqmaxerı ğäiläsenä asraw qız bulıp kilgän. Xuca xatın qatı awıru bulıp urın östendä yatqan. Xuca çäçtaraş bulıp eşli, xalıq telendä iseme erman ikän. Räbiğa awıru xatınnı ber yıl qarağan, ä ul wafat bulğaç, erman-pariqmaxer Räbiğağa xatını bulırğa täqdim itkän. Şul räweşle alar ber ğäilä bulıp yaşi başlağannar. Ul çaqta ermannıñ üz çäçtaraşxanäse bulğan, Räbiğa şunda cıeştıru, yuwu, seberü eşlären başqarğan.

Erman belän Räbiğanıñ ber malayları tuğan, tik ğömerle bulmağan, 12 yäşe tulğanda awırıp ülgän.

1925 yılda ermannıñ xosusıy çäçtaraşxanäsen natsionalizatsiyälägännär, däwlätneke itkännär, ermannıñ üzenä şunda ğädi çäçtaraş bulıp eşlärgä röxsät itkännär. Däwlätkä eşläw östenä erman elekke klientlarınıñ öyenä yörep tä xezmät kürsätkän, şularnıñ berse bezneñ äti bulğandır inde.

1938 yılda, ermannı qulğa alıp, Plätän törmäsenä yapqannar, böten milken konfiskatsiyälägännär. Räbiğanı soraw aluğa çaqırıp, «İreñ pistoletın kaya yäşerde?» dip tinterätkännär. Räbiğa: «Min anıñ pistoletn kürgänem yuk», dip cawap birä, ä soraw aluçı atna sayın çaqırtıp şul uq sorawnı qabatlıy ikän.

Şul doproslardan qotılu çarasın ezläp, Räbiğa ber iptäş xatınına möräcäğät itkän. Tegese mondıy kiñäş birgän: «Anıñ pistoletı ıştan töbendä, min bütän pistoletın belmim», - dip äyt sin alarğa digän. Çirattağı doproska barğaç Räbiğa iptäş xatını öyrätkän süzlärne yarıp salğan. Şul süzlärdän soñ soraw

aluçı bik qatı açulanğan, Räbiğanı xuliğan dip, başqa äşäke süzlär belän sügep, qäbinetınnan quwıp çığarğan, soraw alırğa bütän çaqırmağan.

1941 yılnıñ başında, Räbiğanı törmä qapqasına çaqırtıp, ireneñ kiyemnären tapşırğannar. Ber tanış militsioner ire ermannıñ şpionlıqta ğayıplänep atıp üterelüwen äytkän.

Menä şulay tırış, eş soyuçän pariqmaxer erman faciğäle ülemgä duçar bula - tuğan cire Qazanda ber ğayıpsezgä atıp üterelä. Anıñ xatını Räbiğa gomereneñ soñğı könnärenä qädär berençe iren - erman-pariqmaxernı cılı süzlär belän iskä aldı, xodaydan aña cännätlär sorap doğalar uqıdı.

**Usiyädän - tuğan yortqa**

**Bez ğäilädä öç malay üstek. Yäş aralarıbız ikeşär yıl. İñ keçese min - Marat, urtançıbız Nämiq häm iñ olıbız Nayad. Tuğannan birle 1943 yılğa qädär Qazannıñ Qayum Nasıyri uramındağı 10 yortta yäşädek. Buyortqa 60-70 nçe yıllarda ğına iğtibar itä başladılar. Çönki anı tatar xalqınıñ böyek mäğrifätçese, tarixçı häm filosof Şihabetdin Märcäni saldırğan, 1858-1889 yıllarda şunda yäşägän.**

**Xäzerge köndä bez torğan Märcani yortınıñ xäle elekkedän ällä ni ayırılmıy: qapqasın timerdän yasağannar da işek aldına asfalt cäygännär. Qazannıñ 1000 yıllıq yübileyena bez bu yort çın-çınında arxiteqtura häykäle bulır dip uylıybız. Bügen «Mäğrifät» uquçılarına abıem Nämiqnıñ istälek däftärennän ber säxifä täqdim itäm. Qazanıbız yübileye aldınnan ul uquçılarğa qızıqlı bulır dip ömetlänäm.**

**Marat ŞAMMASOV.**
**Cälil bistäse,**
**Sarman rayonı.**

1942 yılnıñ avgustı. Paroxod, nihayät, Qazan pristanena tuqtadı. Yar buyındağı suda mazut tapları, ağaç kisäkläre yözep yöri. Yardağı kom östendä çüp-çar, çüpräk-çaprak häm pıyala watıqları küp. Gomumän, tirä-yaq küptän inde cıyıştırılmağan. Şulay da yarğa töşep, tuğan yaq cirenä ayaq basu üze canğa cılılıq birä.

Qazan pristane Bişbalta bistäsendä urnaşqan. Pristan tiräsen Qazan xalqı, rusça «ustye» süzennän alıp, Usiyä dip tä

yörtä. Usiyä xalıq öçen İdelgä çığu qapqası ğına tügel, ä yal itü urını da. Menä yazğı boz quzğalu waqıtı citä. Şähärdäge tramvay wagonnarına boz ağuwın qararğa öndäwçe plaqatlar elenä. Xalıq Kazansu küpere häm Bişbalta dambası buylap, tramvay wagonnarına tulıp yäisä cäyäwläp, Usiyäğa ağıla. İdel yarlarınnan talyan ğarmunı, cır tawışları işetelep tora. Qäyber ğäilälär, yar buyında samawır şawlatıp, çäy dä eçep utıralar. İdeldä boz quzğalu - şähär xalqı öçen üze ber bäyräm.

Menä matur cäy kilä. Usiyä tiräsendä yal itüçe xalıq kübäyä. Alar Markiz dip atalğan kom utrawlarına yünälä. Anıñ çista komı, sözäk yarları keşelärgä su koenu, yal itü öçen maxsus yasalğan diyärseñ. Su tramwayları yal itüçelärne Usiyä belän Markiz arasında köne buyı arlı-birle taşıp tora.

Bilgele, mondıy küñelle xällärgä suğış nokta quydı. Xäzer isä minem tizräk öygä qaytıp citäse, tuğannarnı küräse kilä. Bişbalta dambası buylap, balaçaqtan tanış urınnarnı küzätep cäyäw atlıym.

Tatarstan uramınıñ Nasıyriğa qarşı yağında cirgä señep betkän keçkenä genä kerosin kibete bar. Şul kibet işege töbendä ozın çirat suzılğan. Kitergän kerosin citmi qala, şuña kürä çirat tön buyı saqlana.

Nasıyri çatındağı ipi kibetenä dä ozın çirat suzılğan. Nasıyri uramı, şähärneñ başqa uramnarı kebek ük, yarım cimerek xäldä. Uramğa tüşälgän aq taş küptän yañartılmağan, yulda çoqırçaqırlar barlıqqa kilgän. Uramnıñ ike yağınnan suzılğan trotuar da gel çoqırlardan tora. Cöp sanlı yortlar yağında qapqalarnıñ berse genä saqlanıp qalğan, başqalarınıñ bağanaları ğına tora, bezneñ yort qapqasınıñ da bağanaları çitkä yantayğan.

Uramnıñ qarşı yağındağı yortlar kürer küzgä şaqtıy tözek. Uram çatındağı berençe bina Tatarstan uramı buylap Komsomolskaya çatındağı cimerek çirkäwgä qädär suzıla. Ul elek monastır bulğan dilär. Çattan ikençe yort işşeğaldındağı taş binada rayon sudı urnaşqan. Suğışqa xätle Märcani mäçeteneñ ap-aq stenaları uramğa yam kertep toralar ide. Xäzer isä, buyawlarnı yañartu ğına tügel, kiresençö, mäçet işeğaldında deget skladı yasağannar. Mäçet qartlarına deget miçkäläre arasınnan uzarğa turı kilä.

Nasıyri uramınıñ mäçet çatında su kolonkası quyılğan. Su äkren agu säbäple, anıñ yanında xalıq ber dä özelmi. Monnan alğan sunı eçärgä genä totalar. Ker yuwu öçen Qaban küle buyında urnaşqan moyqa xezmät itä. Moyqa - qalın taqta tüşäp yasalğan zur sal. Ul timer troslar belän yarğa tarttırıp berketelgän. Baştaraq sal östendä tübäle qorılma da bar ide, soñraq ul cimerelep bette häm

sal östendä idän genä qaldı. Jäy könnärendä moyqada ker yuwuçı xatınnarnıñ ker bäläklägän tawışları işetelep tora. Qış könnärendä dä moyqa tiräsendäge bäkelärdä ker çayqawçılar betmi.

Nasıyri uramınıñ mäçetkä qarşı çatında ike qatlı keçkenä genä ağaç yortnıñ asqı qat täräzäläre cirgä tiyep ük tora. Menä şul yortta kürenekle tatar mäğrifätçese Qayum Nasıyri yäşägän. Bezneñ uramğa anıñ iseme birelgän.

Qapqadan kergäç uñ qul yaqtağı binanıñ bärençe qatındağı zur täräzäläre häm biyek paradnıy işege küzgä taşlana. Sul yaqtağı bina başqaça tözelgän: anıñ täräzäläre keçkenä häm cirdän yartı metr çaması ğına qalqıp tora. Bu binanı tözetüçe xuca ber ğäilä öçen uñaylı şartlar buldırunı küz aldında totqan bulsa kiräk. Şuşı yortta ğäiläse belän Şihabetdin Märcani yäşägän. Revolyutsiyä aldınnan yortnıñ xucası Borhan mulla bulğan dip söylilär.

## Mäşäqätle uqu yılları

Yort basqıçı buylap menyıp, min gomum koridor işegen tartıp qaradım. İşek açılırlıq, eçtän keläse elenmägän buldı. İşek yañağındağı elektr lampoçqasın yandırıp cibärgän idem, üzebezneñ işektäge zur yozaqnı kürep aldım, Bu xäl miña ğäcäp toyıldı.
Çönki min öydän çığıp kitk ändä bezneñ ğäilädän ätine genä armiyägä alğannar ide. Anı, yäşe olı (48 yäş) häm isänlege naçar buluğa qaramastan, «nestroyıwoy» kategoriyäsenä kertep, Zelenodolskidağı xärbi zavodka raznoraboçiy itep mobilizatsiyälägännär ide.
Koridorğa qarağan Täzkirä apa işegennän söyläşkän tawışlar işetelde. Min işekne şaqıp Täzkirä apalarğa kerdem. İşektän sul yaqta, miç aldında minem däw äni utın ağaçınnan çıra telä ide. Täzkirä apa üzeneñ keçkenä samowarın çistarta. Alar: «Nämiq qayttı, isän-saw, äydä, uz!» - dip, şatlanıp qarşı aldılar. Täzkirä apa samowarın quyarğa gomum koridorğa çığıp kitte. Min üzemneñ çemodannan yartı kirpeç ipi häm qalğan 200 gramm çaması şikär qomın östälgä alıp quydım. Çäy eçkändä däw äni ätineñ haman Zelenodolskida eşläwen, 18 awğustta abıem Nayadneñ suğışqa alınuwın, ä avgust azağında änineñ dä, enem Maratnı alıp, Yudinodan eraq tügel Cäke isemle tatar awılına uqıtuçılıq eşenä kitüwe turında söyläde. Min Qazannan çığıp kitkändä, äni eşlägän tatar mäktäben yabıp, uqıtuçıların xärbi zavodka raznoraboçiy itep jibärgännär ide. Xäzer, anıñ yuğarı belemle

tatar tele uqıtuçısı buluwın iskä alıp, Jäkedäge tatar urta mäktäbenä cibärgännär.
İkençe könne irtän ük prigorodnıy poezdga utırıp min äti yanına kittem. Anda minem elek tä barğanım bar ide. Paratski stantsiyäsenä xätle poezd belän barasıñ da, annan eraq tütel obşçejitie bulıp qalğan zur baraqlar bar. Şul baraqlarnıñ bersendä ike qatlı ozın narlarnıñ ber öleşendä ätineñ iske odeyalı häm qapçığı yata. Şul bilgelärgä qarap, ätineñ nardağı urının taptım. Nar astındağı qapçıqtan berniçä bäräñge alıp, alarnı peşerep quyarğa buldım. Ätineñ koteloğına su salıp, anı baraq urtasında yanıp torğan «burjuyqa»ğa utırttım. Tışqa çığıp, umıwalniqta bäräñgelärne yudım da qaynap çıqqan koteloqtağı suğa saldım. Ozaq ta ütmäde, äti eştän qayttı. Anıñ beraz ikmäge dä bar ikän, şunıñ belän äle peşkän çikmänle bäräñgene aşadıq. Min üzemneñ paroxodta yörep qaytularımnı söylädem. Paroxod şturmanı miña 10 nçı qlassnı tämamlap institutta uqırğa kiñäş birüwen äyttem. Äti şul kiñäşkä quşıldı häm: «Sin bit tırışıp uqıysıñ, mäktäptä uquwıñnı däwam itep, institutqa kerü mäslixät bulır. Ä uquğa tüläwne niçek bulsa da oyıştırırbız,» - dide. Bez äti belän kiläse atnada ikäwläp äni yanına, Cäke awılına barıp qaytırğa söyläştek. Şunnan soñ äti, yañadan zavodka barıp, üzeneñ tsex naçalniğı häm smenşçığı belän rizalaşıp qayttı da yal itärgä yattı. Min, Paratski stantsiyäsenä barıp, prigorodnıy poezdga utırdım da Qazanğa qaytıp kittem.
İkençe atnanıñ bilgelängän könendä min irtänge prigorodnıy poezd belän Yudino stantsiyäsenä barıp töştem. Elekke söyläşü. buyınça anda äti mine kötep tora ide inde. Bez tiz genä vokzalda üzebez alıp kilgän berär kisäk ipi häm ikeşär bäräñge aşadıq ta yulğa çıqtıq. Cäke awılı Yudino stantsiyäsennän 25 çakrım yıraqlıqta didelär. Dimäk, bezne 5-6 säğätle cäyäwle yul kötä. Kön matur, ayaz, äti belän yänäşä bulu häm änine tizräk kürergä omtılular barısı da bezne ruxlandırdılar. Kiçke säğät 4 tä bez Cäke awılına barıp cittek. Anda, keşelärdän soraşıp, uqıtuçı Şammasowanıñ torğan yortın taptıq. Ul iske genä ağaç yort, xucası ber äbi bulıp çıqtı. Ozaq ta ütmäde, äni belän Marat ta qaytıp kerdelär. Äni bäräñge peşerde häm bez awıl ipie belän tuyğançı bäräñge aşadıq, çäy eçtek. Kiçen ozaq qına söyläşep utırdıq. Min İdel buylap paroxodta praktikada yörgän xällärne söylädem. Äni dä miña yañadan mäktäpneñ 10 nçı qlassına kerep uqırğa täqdim itte.

İrtän säğät 4 tä torıp bez äti belän qaytu yulına çıqtıq. Säğät tuğızda Yudino stantsiyäsenä kilep cittek, änilärdän alıp çıqqan azıqlarnı aşadıq ta, poezdga utırıp ikebez ike yaqqa - äti Paratskiğa, min Qazanğa qaytıp kittek.

Sentyabr ayına kerdek, uqu yılı başlanır waqıt. Miña kiçekmästän üzem uqıysı 10 nçı qlassnı tabıp, şunda uqunı däwam itü turında söyläşergä kiräk ide. Suğışqa xätle min Qaban küle buyında urnaşqan 12 nçe nomerlı tatar mäktäbendä uqıdım. Suğış başlanu belän, ul mäktäpne yabıp, anıñ binasında gospital yasadılar. Uquçılarnı qlassları belän törle mäktäplärgä tarattılar. Bezneñ 9 nçı qlassnı Yaña bistädäge 13 nçe mäktäpkä quştılar. Minem öçen ul mäktäp şaqtıy eraq häm uqular da ikeşär smena bulu 12 nçe mäktäp belän çağıştırğanda bik caysız buldı. Ul ğına da tügel, qışqı salqınnar başlanu belän mäktäpneñ cılıtu sisteması eştän çıqtı da, bezneñ qlassnı 40 nçı, annan 47 nçe mäktäplärgä küçerep, öçençe smenada uqıttılar. Bıyıl bezneñ qlassnıñ yañadan 13 nçe mäktäpkä qaytarıluwın işetep, min şunda bardım. Miña däreslärgä yörergä röxsät ittelär, läkin irtägä ük qlass belän bergä Layış rayonındağı kolxozğa eşkä barırğa häm oktyabr ayına xätle yartı yıllıq uqu bäyäsen (150 sum) tülärgä kiräk didelär. İkençe könne irtän, keçkenä genä yançıq totıp, min mäktäpkä bardım. Anda bezne, iske yök maşinasına utırtıp, Layış rayonına alıp kittelär. Bez eşlise kolxoznıñ klubına urnaştıq, qızlarnı fatirlarğa urnaştırdılar. İrtän kolxoz briğädirı bezgä eş urının kürsätte. Ul qır ülän basqan çäçü cire bulıp çıqtı. Anda nindider «strategiçeskiy» üsemlek utırtılğan. Ul üsemlek SK-4 zavodına rezina yasaw öçen kiräk ikän. Ul tışqı yaqtan alo' gölenä oşağan. Qırdağı ülän arasında anı tabuwı da qıyın. Bez tezlänep ülännärne qul belän yolqıp kiläbez dä, alo'ğa oxşağan üsemlekne kürgäç, briğädirnı çaqırıp, añardan tanıttırabız. Şulay itep, berençe könne briğädir belän eşläsäk, başqa könne ul bezneñ yanğa kilmäde. «Sez üzegez gramotnıylar» dip bezgä ışanıç belderde. Bez utağan mäydanda qap-qara cir häm siräk kenä üsep utıruçı alo'ğa oxşağan üsemleklär qala ide. Köndez kolxozdan bezgä ber krujka söt häm ber qıyar birälär ide. İke atna şulay eşläp uzıp kitte dä közge yañğırlar başlandı. Bezgä qaytıp kitärgä röxsät ittelär. Briğädir bezne ber cikkän at belän Qazanğa qädär ozattı.

Oktyabr ayında mäktäptä däreslär başlandı. 10 nçı qlassta barlığı 12 uquçı, şularnıñ ikese genä 12 nçe mäktäptän kilüçelär. Däreslär ikençe smenada, yağni töştän soñ ğına uzdırıla. Däreslärdä paltolarnı kiyep utırabız. Salqınlıq tağın da köçäyep, 13 nçe mäktäptä däreslär uzdırırlıq mömkinlek qalmağaç, bezneñ 10 nçı qlassnı 8 nçe nomerlı rus mäktäbeneñ 10 nçı qlassına quştılar. Bez, 13 nçe mäktäptän kilüçe uquçılar, 4 yeget häm 8 qız bulsaq, rus qlassında 18 qız uquçılar bar. Rus qızları kübesençä zur gäwdälelär, öslärendä yaxşı külmäklär, irennäre häm qaşları buyalğan. Tatar qızlarınıñ kiyenüläre bik ğädi, ä alarnıñ qaş, iren buyawların bez küz aldına da kiterä almıy idek.

Ölgereş yağınnan da tatar uquçıları ruslardan ayırılıp toralar ide. Tatar mäktäbennän kilgännär «yaxşı»ğa uquçılar ide. Çönki «naçar» yäisä «urtaça» bilgeläre alıp uquçılarnı, povestka

belän çaqırıp, FZO mäktäbenä yäisä zavodka eşkä cibärep tordılar. Läkin bezgä rus qlassında barlıq fännärne dä rus telendä üzläşterü awır bulıp toyıldı. Bez, tatar uquçılar, däres-lärdän soñ qalıp bergäläp añlaşa häm öygä birelgän mäs'älä-lärne çişä idek.

Ximiya bezneñ öçen iñ awır fän bulıp çıqtı. 1938 yılğa qädär tatarça yazuda latin xärefläre bulu häm ximik elementlarnıñ yazıluı belän äytelüwe ber bulu ximiya fänen uqığanda bezgä küp ciñellek kitergän bulğan. Xäzer isä ximik elementlarnıñ isem-nären rusça äyter aldınnan bez totlığıp tordıq. Bez, tatar uquçı-lar, awır waqıtlarda ber-berebezgä yärdäm itep, uñışlı uqıp bardıq.

1943 yıl başında äti, yuğarı belemle uqıtuçı bularaq, xärbi zavodta eşläwdän azat itelde häm Tatarstan mäğärif ministrlığı boyırığı belän Yutazı rayonına uqıtuçılıq eşenä cibärelde. 1943 yılnıñ fevral ayında bez ğäilä belän Yutazı rayonına küçep kittek.
Şul rayondağı Käräkäşle urta mäktäben min Maqtaw gramotası belän tämamladım.

## Tağın ber qat Şammasowlar turında

**«Naşa jizn» rayon ğäzetasınıñ «Ellar aşa…» publikatsiyäsendä (7 iyün 2002 yıl), Bäräñgedä egermençe ğasırnıñ 30 nçı yıllarında yäşägän Şammasowlar ğäiläse turında söylände. Ul publikatsiyägä Arizona ştatında (AQŞ) ulı ğäiläsendä yäşägän Nämiq Şammasownıñ ikençe xatı kilep ölgermägän ide. Anda ul Bäräñge peduçilişçesı uqıtuçıları - üzeneñ äti-änise Xälil häm Mösaffa Şammasowlar häm şulay uq üze turında da yaña mäğlümatlar kertkän.**

Minem ätiyem Xälil Nasretdin ulı Şammasov gel qızıq- sınuçan keşe ide, eçkeçelekne, tämäke tartunı ber dä yaratmadı, haman belemgä omtıldı. Tormışnı yaxşıraq tanır öçen ul 1913, yılnıñ aprel ayında eş ezläp Mäskäwgä kitä. Mäskäw, Nikolaev, Xerson şähärläreneñ zavod häm fabriqalarında eşli. Oktyabr revolyutsiyäsen ul Mäskäwdä «Gurlyand şirkäte» eşçeläre qol-lektiwında qarşılağan. Anıñ Samara gubernasında xalıq mäğärife çeltärendä, annan son, Bäräñgedä eşläw çorı turında min yazdım inde.

«Şomlı yıllarda» bezgä Qazanda qwartirğa ike tön rättän çekistlar «qara qozğında» kildelär häm tönnär buyı zur östälneñ aşyawlığı astında saqlanğan şäxsi xatlarnı uqıdılar. Xäterlim, min änigä sıyınıp urın-jir östendä utırdım, qara kün palto kigän

çit keşelärdän qurqıp yoqlıy almadım. İkençe töngä alar üzläre belän ätine alıp kittelär. Annarı bez äni belän ätigä peredaça taşıdıq, ä küreşergä röxsät itmädelär. Ätine yılğa yaqın totqannan soñ cibärdelär. Anıñ äytüwe buyınça, anı millätçelektä ğayıplärgä telägännär.

1942 yılda bezneñ abıy Nayad frontqa kitte, 3 tapqır yaralanıp, barlıq suğışlarnı ütep, Ciñügä barıp citte. Ätine xezmät frontına Zelenodolsk şähäreneñ №4 zavodına, ä änine armiyä öçen çañğı xäzerläwgä eşkä cibärdelär. 1943 yılda, SSSR xökümäteneñ prikazın ütäw yözennän, äti-änine xezmät frontınnan azat itep, Tatarstannıñ Yutazı rayonı mäğärif bülegenä cibärgännär. Alar 1957 yılğa qädär, yağni layıqlı yalğa kitkänçe, şul rayonnıñ Käräkäşle häm Bäyräkä urta mäktäplärendä uqıtuçı bulıp eşlädelär.

Ä bez, Nayad häm Nämiq, belem alırğa berençe adımnarnı abıy belän Bäräñgedä yasadıq. Äle mäktäptä uqığançı, Nayad abıem däres xäzerlägändä, min anıñ yanında utırırğa yarata idem. Anı tıñlap utırıp, uqırğa häm yazarğa öyrändem. Berençe sıynıfqa barğanda, inde min yaxşı ğına uqıy, yaza häm sanıy belä idem. Şuña kürä mine ikençe sıynıfqa küçerdelär. Alda da min barı tik «5»le bilgelärenä genä uqıdım häm urta mäktäpne Maqtaw gramotası belän tämamladım. Uquğa iğtibarlı bulırğa häm anı yaratırğa mine berençe uqıtuçım Wälieva Mönira lümovna häm äti-äniyem öyrättelär. Küp yıllar uzuğa qaramastan, min Bäräñge urta mäktäbe uqıtuçılarına, alarnıñ yäş buwınnı tärbiyäläwdä namuslı xezmätlärenä üzemneñ zur räxmätemne belderäm.

**H. ŞAMMASOV,**
**xezmät veteranı, texnik fännär qändidatı,**
**Arizona ştatı, AQŞ.**
**F. MÖXÄMMÄTOWA.**

## Berençe baru

«Aeroflot» oçqıçı bezne Xabarowskidan San-Frantsisko a'roportına alıp kilde. Şulay itep, 1992 yılnıñ 20 ğıynwarında, irtänge säğät 9da bez, Nämiq belän Nailä, Ameriqa Quşma Ştatlarına ayaq bastıq. Bezne qarşı alırğa kilgän ulıbız Ayrat belän küreştek tä, yänä oçqıçta ulıbız torğan şähärgä - Fenikska yul tottıq.

Feniks a'roportı şähär urtasında urnaşqan. Şundağı ğarajda qaldırğan awtomobilenä utırtıp, ulıbız bezne fatirına alıp qaytıp kitte.

Şähär eçe buluğa qaramastan, yulda svetoforlar yuq. «Fri vey» (irekle yul) dip atalğan maxsus tiz yörü yulı bar, ul här yaqqa biş-altı polosalı. Yuldan-yulğa küçü isä timer-beton küperlär yärdämendä başqarıla. Bez barası yort şähär eçendäge şähärdä - lendeylda urnaşqan ikän. Yort xucası, 80 yäşlek Ewelin xanım, bezne açıq yöz belän qarşı aldı. Ewelinnıñ äti-änise bezdäge grajdannar suğışı yıllarında Rusiyädän küçep kilgän, ä Ewelin üze Ameriqada tuğan, urısça bötenläy belmi.

Bergäläp çäy eçtek tä, Ayrat bezne ber qunaqxanägä iltep urnaştırdı. Ameriqadağı ğädät buyınça, çittän kilgän tuğannar qunaqxanädä yäşilär ikän. «Şuña kürä min Ewelinğa sezne qundıru turında süz qatmadım», - dide ulıbız. Bez qunaqxanädä ayırım apartamentqa urnaşuwıbızğa qänäğät ikänlegebezne äyttek.

- İrtägä irtänge säğät unnarda Ewelin telefonnan çıltıratır da, sezne kilep alıp, ber-ike kibet kürsäter. Ber törle dä azıq-tölek almağız, eştän qaytışlıy üzem kertep çığarmın, - dip, Ayrat qaytıp kitte…

İkençe könne irtän Ewelin, kiläsen aldan xäbär itep, annarı bezne üz awtomobilenä utırtıp, azıq-tölek kibetenä - super- marketqa alıp kitte. Ber qwartalğa suzılğan supermarketqa kilep kergäç, aşamlıqlar tulı kiştälärne kürep, xäyran qaldıq. Bez Rusiyädän kitkändä azıq-tölek kibetläreneñ kiştäläre buş ide diyärlek, qalay sawıtlarda barı diñgez käbestäse genä tora ide. Rizıq tulı kiştälär arasına kergäç, keçkenä arba citäklägän Ewelinnan: «Bu xätle küp produktnı kemnär alıp beterä soñ?» - dip soradıq. Ul, här rizıqnı kimegän sayın östäp toralar, ä yaraqlılıq waqıtı çıqqannarın alıştıralar, dip añlattı.

Beraz yörgäç, Ewelin menedjer yanına kerep çığam dip kitkän ide, ozaq ta tormıyça, menedjer belän bergäläp kilep çıqtı. Tegese, azıq-tölek tutırılğan zur käğaz törgäkne bezgä birep:

- Bu- bezneñ kibet xezmätkärlärennän sezgä büläk, - dide. Çığu yulına qädär ozatıp, qabat üzlärenä çaqırıp qaldı. Qaytqaç kürdek: törgäktä tuñdırılğan tawıq botları, döge yarması, vermişel, şikär komı, «Lipton» çäye, keçkenä şeşädä sıyıq may, aq kümäç häm bütän rizıqlar bar ide. Bez ul rizıqlarnı berniçä kön aşadıq.

Ameriqannar bik açıq yözle keşelär ikän, çit keşe belän dä yılmayıp isänläşälär. Awaz belän isänläşkändä üz işlärenä «hay» dip kenä däşsälär, bezneñ kebek olı yäştägelärgä «hellou» dilär, «haw du yu du» dip tä östilär. Bez dä isänläşkändä, cawap itep «hellou» süzen qullandıq, çönki «hay» digäne bezgä matur bulıp toyılmadı.

Ber könne Ayratnıñ xezmättäş dustı, injener Ralf Gofman bezne qunaqqa çaqırdı. Yul buyı Ayrat bezgä ameriqannarnıñ qunaq qarşı alu üzençäleklären söyläp bardı. Näk çaqırılğan waqıtqa

kilep citä almasa, qunaq telefon aşa monı xäbär itärgä tiyeş. Qunaq kiläse waqıttan soñ 15 minut uzsa, xuca işekne bikläp quyarğa mömkin - moña xaqı bar. Kilgän keşe, öygä kergäç, ğädättä, ayaq kiyemen salmıy. Çönki bu ildä berkem dä cäyäw yörmi,ä awtomobildän töşkäç utäse yul, yort işeğaldı çip-çista. Ameriqannar başlı-küzle bulu belän ayırım yortta yäşärgä omtılalar häm şuña ireşälär dä. Çönki eşläwçelärgä banqlar kiräk qädär ssuda birälär.

… Yartı säğät çaması fri-veydan kilep, ber qatlı kottedj-lar uramına kerdek tä, ber yort qarşında tuqtadıq. Monda berniçä avtomobil tora ide inde. Tışqı işektän bezne Ralf üze qarşı aldı. Yılmayıp isänläşte, isänlek-sawlıqnı beleşte dä: «Ameriqanı oşattığızmı?» - dip soradı. Ğädättä, ameriqannar isänläşü belän şul sorawnı birälär. «Bezgä ameriqannarnıñ açıq yözle buluwı, dustanälege oşıy», - kebegräk cawap işetkäç, üz xalqı öçen gorurlanuların sizdertälär.

Ralf bezne, öyenä çaqırıp kertep, zal çitendäge quxnya kebegräk urınğa alıp kilde. Quxnya biredä ayırım ber bülmädä tügel, ä zaldan prilavok-bar östäle aşa ğına ayırılıp tora. Quxnyada aş-su äzerläwçe xanım - Ralfnıñ tormış iptäşe Jakis belän isänläştek. Annarı Ralf bezgä yortın kürsätep yörde. Yortta öç zur bülmä bar, ikese - yoqı öçen, ä berse - kompyuter bülmäse. Yoqı bülmäseneñ berse yanında bädräf häm yuwınu büleme (vanna, duş). Ä ikençe bädräf - koridor yağında, kilgän qunaqlar şunnan faydalana ikän. Yortnıñ artqı yağında bek-yard, yağni keçkenä genä baqça. Baqça urtasında - basseyn, ä baqça tiräli limon, äflisun ağaçları üsep utıra. Baqçağa uramnan kerü qapqası bikle tora. Şul qapqa belän yort arasında ike avtomobil sıyarlıq ğaraj eşlängän. Ğarajğa yort eçennän dä çığıp bula: ul oçraqta ber bülmä aşa çığarğa kiräk. Anda isä ker yuwu maşinası tora. Kiştälärdä törle xucalıq kiräk-yaraqları. Gomumän, yortnıñ eçe dä, tirä-yağı da cıynaq, pöxtä kürenä.

«Minem babalarım Ameriqağa Berençe bötendönya suğışı yıllarında ermaniyädän kilep urnaşqannar», - dide Ralf. Dimäk, här eştä tärtip, pöxtälek yaratuçı alman (nimes) millätenä xas sıyfatlar üzenä dä yat tügel. Ayrat bu xälgä açıqlıq kertte. Gomumän dä, aqş xalqınıñ kübesen çit illärdän kilgän keşelär immiğrantlar täşkil itä ikän. här immigrant üze qaldırıp kitkän ilneñ goref-ğädätlären totarğa tırışa. Bu xäl isä törle kulturalarnıñ üzara sıyışıp yäşäwen kiterep çığara. Şuñadır, küp törle kulturalar bergä cıyılğan Nyu-Yorq şähären qaynap toruçı qazan - melting pot dip tä atıylar. AQŞ Konstitutsiyäse küptörle-lekneñ duslığın täşkil itä.

Şulay äñgämäläşep yörgändä, Jakis bezne zalğa kerergä häm qunaq bulırğa, rizıqtan awız itärgä çaqırdı. Quxnya aldındağı bar östälendä törle qabımlıqlar, peşkän tawıq, eçemleklär tezelgän. Ber başta plastmass tälinkälär, staqannar, qaşıq-çäneçke-pıçaqlar salınğan tartmalar tora, härkem tälinkälärgä üzenä kiräk qädär azıq salıp, staqannarğa sular

ağızıp alıp, verandaga (patio) çıqtıq ta, östäl tiräli utırıştıq. Şulay aşap-eçep, gäpläşkändä, yanıbızğa ber yäş kenä xatın-qız kilde dä, utırırğa röxsät soradı. Ul Palestinadan kilgän student qız Şahidä ikän, monda universitetta uqıy. Bezneñ möselman ikänebezne belgäç. Ul dulqınlanıp kitte, şatlandı. Kiläçäktä Palestina da, kürşe-tirädäge islam däwlätläre kebek, irekle, möstäqıyl bulır digän ömet belderde. Şahidägä uquwında uñışlar telädek. Ğäräp qızı büläk itep birgän medalne - Palestinanıñ simvolın äle dä istälek itep saqlıybız.Sanawlı könnär tiz uzıp kitte, bik eçtälekle buldı. Şul arada ulıbız bezne Arizona ştatınıñ törek-ameriqan cämğıyate belän tanıştırdı. Küp kenä ameriqalı töreklär belän küreştek, mäcleslärenÑdä buldıq. Cämğıyat citäkçelärennän berse Nikki xanım Muradoğlı, awtomobilenä utırtıp, bezne şähärneñ tirä- yağında yörtep qaytardı. Ciz mäğdäne çığarılğan şaxta muzeyen, kovboylar yaşi torğan traktirlı bistäne, yaña tözelgän gospitalne (soñğısı xatınım Nailäne ayıruça qızıqsındırdı), biş yoldızlı qunaqxanälärne häm başqa matur binalarnı qaradıq. Şulay itep, ber ay eçendä küp yaxşı keşelär belän tanıştıq. Kiläçäktä dä alar belän oçraşırğa yazsın.

Fewralneñ 20sendä Ayrat bezne a'roportqa iltte häm bez, kilgän yul belän, Mäskäwgä oçtıq. Bu 1992 yıl ide. Ä xäzer bez AQŞta yäşäp yatabız. Bu yulı ozakqaraq kildek. Xäyer, qalğanın tağı yazarbız ele.

**Nailä häm Nämiq ŞAMMASOWlar.**
**Kaliforniyä tatarları cämğıyate**

Ameriqağa çirattağı ber baruda bezne San-Frantsisqoğa tatarlar cämğıyate kontsyırtına çaqırdılar. Cämğıyatneñ idarä äğzası Räqıya xanım Mansur qunaqxanägä urnaşuda häm kontsert zalına kerüdä bezgä bulışlıq kürsätäçägen äytte. Bu 1995 yılnıñ noyabr ayı ide. Bez, Fenikstan samolet belän ike säğät çaması oçıp, San-Frantsisko a'roportına barıp töştek. Ulıbız Ayrat waqıtlıça qullanıp toru öçen aeropot ğarajınnan aqça tüläp ciñel avtomobil aldı, bezne yaqındaraq urnaşqan «Mariott» qunaq-xanäsenä alıp kilde. Qunaqxanä bik zur, küpqatlı binada urnaşqan, anıñ eçke yağı matur itep cihazlanğan. Beleşmälär östälendäge xezmätkär bezneñ öçen ber nomer qaldırıluwın äytte. Qunaqxanä xezmätkäre awtomobilebezne qapqa töbennän alıp ğarajğa kertep quydı, kiräk bulğanda anı üzem kiterep quyarmın, dip, Ayratqa avtomobil açqıçın birde. Ayrat kiräkle käğäzlärgä qul quydı da, yanıbızğa kilep, bezne fotoğa töşerde. (Räsemdä sez Nailä belän Nämiqnı qunaqxanä vestibyülendä küräsez).

Ozaqlamıy ikençe xezmätkär bezne nomerıbızga ozattı, işegen açıp kertep cibärde. Nomerda ike yoqı bülmäse, här bülmädä ike keşelek qarawat, ike känäfi. Zaldan vanna bülmäsenä kerü öçen tağın ber işek bar. Zalda zur diwan, anıñ aldında telewizor, telefon. Yoqı bülmälareneñ işekläre dä zalğa çığa.

Ayrat Räqıya xanımğa telefon aşa bezneñ kilep citüwebezne häm qunaqxanägä urnaşuwıbıznı xäbär itte. Räqıya xanım kontsert bulası qlubnıñ adresın häm baru yulın añlattı. San-Frantsisko uramnarı Feniqstağı kebek turı, tigez tügel, şuña kürä yulğa irtäräk çığu mäslixät bulır dip iskärtte. Nailä peşergän öçpoçmaqlarnı aşap, çäy eçep, yal itärgä yattıq.

İkençe könne irtän, aşap eçkäç, Ayrat bezne awtomobildä şähär uramnarı buylap alıp kitte. Bormalı häm tawlı uramnardan bara torğaç, okean yarına kilep çıqtıq. Awtomobildän töştek, diñgez hawasın sulap, dulqınnar şawın tıñlap basıp tordıq, iyelep, salqın suda qullarıbıznı çılatıp aldıq. Ayrat añlattı: «Mondağı diñgez suwı härwaqıt salqın, xätta qızu cäy könnärendä dä cılınmıy», - dide. Awtomobilgä utırıp, yulıbıznı däwam ittek. Nihayät, kiräkle urınğa, kontsert bulası qlubqa barıp cittek. İşek töbendä bezne Räqıya xanımnıñ ulı qarşı aldı häm zalğa kertep cibärde. Bez zalğa kergändä kereş süzlär äytelep betkän, säxnädä ike rät bulıp basqan mäktäp yäşendäge tatar balaları Ğabdulla Tuqaynıñ «Tuğan tel»en cırlıylar ide. Cırnı bez monnan ber ay elek kenä Mäskäw qlubında İlham Şakirov başqaruwında işetkän bulsaq ta, Ameriqa cirendä tatar yäşläre

Cırlavına bik quwandıq. Çönki cämğıyat eşlärendä yäşlärneñ qatnaşuwı, berençedän, idaräneñ yaxşı eşläwen kürsätä, ikençedän, cämğıyatneñ matur kiläçägenä zur ömet tudıra.

Tänäfes waqıtında zalda da, vestibyuldä dä tatar telendä söyläşülär işetelep tordı. Busı inde Rossiyädä yäşäwçe tatarlar öçen dä ürnäk bulırlıq. Mäskäwdä ütä torğan tatarça kontsertlarda kübräk rusça söyläşülär işetäseñ bit. Räqıya xanım bezneñ yanğa kilep isänläşte, xäl-äxwäl soraştı häm kontsert soñında bergäläp ber mäcleskä barırğa çaqırdı. Tänäfes waqıtında bezneñ belän berniçä tatar yegete kilep isänläşte. Alar sovetlar ileneñ törle şähärlärennän kilgännär, matematiqlar, kompyuterçılar ikän. Ä ber yeget Yutazıdan kilgän bulıp çıqtı. Yutazı - Qazannan eraq ber rayon, 1950 yıllarda bez dä anda yäşägän idek. Şuña kürä Ameriqa tikle Ameriqada Yutazı keşesen oçratu bezgä bik säyer toyıldı.

Kontsyırtta tatarça häm törekçä cırlar başqarıldı, biyüçelär tatarça biyedelär. Kontsert tulısınça cämğıyatneñ üz köçe belän genä äzerlängän buluğa qaramastan, bez anı qänäğätlänü belän qaradıq, oşattıq. Kontsert betü belän Räqıya xanım bezneñ yanğa kilep, çığış yasawçılar turında fikerlärebezne beleşte. «Xor da, biyüçelär dä, üzläreneñ yal waqıtların qızğanmıyça, bik tırışıp äzerlän-gännär, bez kontserttan bik qänäğät», - didek.

Şunnan soñ, üz awtomobilebezgä utırıp, Räqıya xanımnıñ avtomobile artınnan mäjles bulası yortqa kittek. Bormalı yullardan aşıqmıyça ğına bara torğaç, ürgä menä torğan ber yulğa borıldıq. Ür başındağı ayırım yortlarnıñ berse qarşına kilep

tuqtadıq. Ul Salix äfände belän Şämsiyä xanım yaşi torğan yort bulıp çıqtı. Xucalar bezne bik şatlanıp qarşı aldılar, tabınğa utırttılar. Tür başında Sälix äfände belän Şämsiyä xanım üzläre urın aldı.

Aşaw-eçüdän berazğa ayırılıp, barıbız da östälneñ ber başınaraq cıyıldıq ta, fotoräsemgä töştek. Şul räsemdä östäl tiräsenä utırğannar (suldan uñğa) Rifat äfände belän Räşidä xanım Ötüşlär, Salix äfände belän Şämsiyä xanım Apaqaylar, Nailä xanım ulı Ayrat belän (Nämiq artqa basqan), Räqıya Safa häm tağın ber xanım. Östäl türenä basqannar Räqıya xanım Mansur (aq qoftadan) änise (sul yağında) häm señelese Märyam belän. Östälneñ sul yağında basıp toruçılar kübesençä kontsyırtta qatnaşuçı yäşlär.

Östäl yanında süz kübräk kontsyırtnı äzerläw turında bardı. Çınnan da, şundıy zur kontsyırtnı 100 urınlı tulı zalda kürsätü öçen oeştıruçılarnıñ häm başqaruçılarnıñ fidakar tırış-lığı kiräk bulğandır.

Bezne şulay uq tatarlarnıñ Kaliforniyä ştatına kilep urnaşu häm cämğıyat oyıştırıp yäşäw tarixı da qızıqsındırdı. Salix äfändeneñ añlatuwı buyınça, xäzerge waqıtta Kaliforniyä ştatında, San-Frantsisqoda yäşäwçe tatarlarnıñ kübese törle yıllarda Rossiyädän Mançjuriyägä, Yaponiyägä häm Törkiyägä kitkän tatarlarnıñ balaları yäisä onıqları. Alarnıñ biredä cämğıyat oeştıru yazmaları Xalidä xanım Deuşta saqlanğan bulırğa mömkin ikän. Şulay uq här ğäiläneñ qızıqsınu tudırırlıq üz tarixı bar, dip tä östäde Salix äfände.

Östäl yanınnan quzğalğaç, bez pianino yanına kilep, kümäkläp tatarça cırlar cırladıq. Şämsiyä xanım belän Nailäneñ G. Tuqay süzlärenä «Täftiläw»ne cırlawı barıbızğa da oşadı. Soñınnan ber oçraşuda Xalidä xanım bezne San-Frantsisko tatar cämğıyate oeştıru turında tübändäge mäğlümatlar belän tanıştırdı.

San-Frantsisqoda 1924 yılda berençe bulıp urnaşqannardan Xäsän äfände Salixov ğäiläsen, Motıygulla Ğärifullin ğäiläsen häm Ğabdulla äfände Zäynäşevne äytergä bula. Alar üzara yöreşep, küreşep yäşilär häm yaña kilgän tatarlarnı üzlärenä yaqınlaştıralar. Şulay söyläşulär waqıtında tatarlarnı ber-läşterüçe oeşma tözü zarurlığı açıqlana.

1960 yılda berençe kümäk cıyılışta oeşma tözü turında qarar qabul itelä. Anıñ räsmi isemen «Ameriqa Törki-Tatar oyışması» dip quyarğa bulalar. Oyışmanıñ töp burıçı itep dini-mädäni häm cämğıyatkä qarağan eşlärne başqaru bilgelänä. Kiñäşle eş tarqalmas dilär bit, oyışmanıñ tormışın kiñäşle räweştä alıp baru öçen idarä saylap quela. Berençe idarägä 9 keşe kerä: Zahidulla Agiş - räis, Säğıyd Kilki - räis urınbasarı, Räşit Aqçurin, Räbiğa Bigi, Rauza Roğard, Mäxmüd Deuş, F.Ğäzizov, Yosıf Diqaprio, Räbiğa Ägerce - idarä äğzaları. Şul waqıtta Kaliforniyä xökümäte tatarlarnıñ dini-mädäni oyışmasın etnik törkem bularaq räsmi räweştä tanıy häm härtörle salımnardan azat itüwen belderä.

İdarä cämğıyat eşlären başqaruda cawaplı keşelärne bilgeli, ber bina satıp alu häm tözekländerü eşlären başqara.


Mäktäp yäşendäge balalar öçen tatar telendä din däresläre açıla. Däreslärne Tasiyä xanım Kilki häm Şämsiyä xanım Apaqay uñışlı alıp baralar. Xanımnar bülekçäse, yäşlär tügäräge ayırım-ayırım yäisä bergäläşep bäyrämnärne küñelle itep ütkärü, tatarça pesalarnı säxnägä quyu, başqa tör massakülämağartu eşlären oeştıralar. Bu eşlärdä Salix äfände belän Şämsiyä xanım Apaqaylar, Xalidä xanım Deuş, Rauza Roğard, Räqıya Mansur, Närkis Geling häm başqalar daimi räweştä aktiv qatnaşalar.

Kaliforniyä tatar cämğıyateneñ tarixı yazılırğa, dönya kürergä tiyeş. Bu yünäleştä Muazziz Baybulatnıñ «Tampere islam cämğıyate: nigeze häm tarixı» (Finlyändiyä) digän tirän eçtälekle, küp illyüstratsiyäle kitabı ürnäk bulıp tora.



Хәлил Шаммасов һәм
Мосаффа Шаммасова.
1950 ел. Ютаза.

Halil Shammasov and
Mosaffa Shammasov.
1950 in Utaza, Tatarstan, Russia



Хәлил Шаммасов (артта баскан) уллары белән.
Утырганнар (сулдан уңга) Марат, Нәмикъ, Наядь

Khalil Shammasov (standing up) with his sons.
Seated (from left to right) Marat, Namik, Naiyad



Нәмикъ, Наилә. 2005 ел. Phoenix, АКШ
Namik, Nailya. 2005. Phoenix,Arizona, USA



Без АТА татар җәмгыяте белән Нью-Йоркта пикникта

With ATA (American Tatar Association) Tatar community on a picnic in New York



Сан-Франциско төрки-татар җәмгыятендә (АТТА):
(сулдан уңга, утырганнар) Лилия, Диляра
(җәмгыятьнең музыка җитәкчесе) кызы белән, Наилә,
Роза (безнең кодагый), Рәшидә …; (басканнар):
Җунейт Чапаноглу Диляраның ире улы белән, Айрат
(улы Рәшид белән) Нәмикъ, … (Рәшидәнең ире)

In the Turkic-Tatar community of San Francisco:
(from left to right, sitting) Lilia, Dilara Chapanoglu
(music director of the society) with his daughter Omet, Naila Shammas,
Ravza Gali, Rashida ( top):
Zuneyt Chapanoglu with their son, Airat Shammas
(with his son Rashid), Namik Shammas, Rashida's husband



Шаммасовлар гаиләсе:
(сулдан уңга) Нәмикъ, Наилә, Айрат (артында
баскан Рәшид). Лилия

The Shammas family:
(from left to right) Namik, Nailya, Airat, Lilia
(Behind everyone is Rashid).



Безнең Америкадагы татар галиме Әдип Невер һәм
хатыны Камилә белән
Edip Niver (top left), his wife Camila (bottom left), and Naila, Namik(top)
and Lilia and Rashit of the Shammas Family

Шаммасовлар гаиләсе:
(сулдан уңга) Лилия улы Самир белән,
Айрат, Нәмикъ, Наилә, Рәшид

The Shammasov family (from left to right): Samir, Lilia, Airat, Namik, Naila, Rashid
(from left to right) Lilia with her son Samir,
Airat, Namik, Naila, Rashid





Shammas Family in 2011, from left to right, Samir (2), Airat (52), Lilia (40), Nailya (86), Rashid (10), Namik (85)